| Бюджет кытлыкларын финанслауның башка чыганакларын бүтән финанс активлары исәбеннән киметү | 01 06 06 00 00 0000 600 | 64 250 000,0 |
| Кредит оешмаларында Россия Федерациясе валютасында һәм чит ил валютасында депозитларга урнаштырылган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә Татарстан Республикасы милкендәге башка финанс активларын киметү | 01 06 06 08 02 0000 610 | 64 250 000,0 |
| Барлык чыганаклар | | 6 591 666,9 |

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 755. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Ана даны – Материнская слава» медале белән аналар – Татарстан Республикасы территориясендә кимендә биш ел яшәүче, биш һәм күбрәк бала тудырган һәм тәрбияләп үстерүче (тәрбияләп үстергән), кимендә бер балигъ булмаган баласы булган Россия Федерациясе гражданнары бүләкләнә.

Бүләкләнүгә үз балаларын тәрбияләүгә намуслы караучы, балаларның сәламәтлеге, белем алуы, физик, рухи һәм

әхлакый үсеше, аларның шәхесен тулы һәм камил үстерү турында тиешле дәрәҗәдә кайгыртуны тәэмин итүче, балалар тәрбияләүдә үрнәк булып торучы аналар тәкъдим ителә.»;

2) 13 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«$10^1$ ) «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре»;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $27^1$ пункт өстәргә:

«$27^1$) «Татарстан Республикасының Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре»;»;

3) 14 статьяда:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) «Татарстан Республикасының Атказанган табибы» – белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче, медицина оешмаларының, санитария-профилактика, шифаханә-курорт учреждениеләренең, сәламәтлек саклау, халыкны социаль яклау буенча башка учреждениеләрнең, фәнни-тикшеренү институтларының, уку йортларының югары профессиональ табибларына, сәламәтлек саклау һәм санитария-эпидемиология күзәтчелеге органнарының табиблык белгечлегенә ия хезмәткәрләренә халыкның сәламәтлеген саклаудагы, дәвалау-профилактика ярдәмен медицина фәненең һәм техникасының заманча казанышларын эштә файдаланып оештырудагы, медицина кадрлары әзерләүдәге казанышлары өчен;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) «Татарстан Республикасының Атказанган газ тармагы хезмәткәре» – газ-транспорт, газ бүлү, фәнни-тикшеренү, технологик һәм проект-конструкторлык оешмаларының, уку йортларының тармакта кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ эшчеләренә, мастерларына, инженер-техник, фәнни һәм фәнни-педагогик хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы территориясендә газүткәргечләр төзүдәге, модернизацияләүдәге һәм эксплуатацияләүдәге, халык һәм сәнәгатьнең төрле тармаклары ихтыяҗлары өчен газны тоткарлыксыз транспортировкалауны тәэмин итүдәге, газ сәнәгате өчен квалификацияле кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен;»;

в) 24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24) «Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» – сәламәтлек саклау өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле медицина персоналына, провизорларга, фармацевтларга, инженер-техник хезмәткәрләргә һәм медицина оешмаларының, шифаханә-курорт, даруханә учреждениеләренең, сәламәтлек саклау, халыкны социаль яклау органнарының, фәнни-тикшеренү, медицина һәм фармацевтика институтларының, барлык ведомство буйсынуындагы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның башка хезмәткәрләренә халыкның сәламәтлеген саклаудагы, медицина ярдәменең һәм дарулар белән тәэмин итүнең сыйфатын күтәрүдәге казанышлары өчен;»;

г) 25 пунктта «матбугатның, нәшриятның, полиграфия сәнәгатенең һәм китап сәүдәсенең,» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле $26^1$ пункт өстәргә:

«$26^1$) «Татарстан Республикасының Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» – матбугат, массакүләм коммуникацияләр оешмаларының һәм органнарының, шул исәптән нәшриятларның, полиграфия предприятиеләренең, шулай ук матбугат хезмәтләренең әлеге өлкәдә кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле хезмәткәрләренә матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсен торгызудагы һәм үстерүдәге казанышлары өчен;»;

4) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе, шулай ук үтенечнамәгә кушып бирелә торган документларның һәм белешмәләрнең исемлеге, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының төрле дәүләт бүләкләре белән бүләкләү үзенчәлекләре исәпкә алына.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне җирле үзидарә органнары һәм республика башкарма хакимият органнары тарафыннан алдан карау билгеләнергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәне җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәнең каралуын гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан карау түбәндәге очракларда туктатыла:

1) Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамә язылган гражданның Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүгә лаеклы булырлык затларга карата Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турындагы законнарда куелган таләпләргә туры килмәве ачыкланса;

2) әлеге Законның 21 статьясында каралган нигезләр барлыкка килсә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртипне бозып кертелсә.»;

5) 23 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән яңа казанышлар өчен бүләкләү Россия Федерациясе дәүләт бүләген яисә Татарстан Республикасының моннан алдагы дәүләт бүләген алганнан соң биш ел узмыйча мөмкин түгел, моңа гражданлык батырлыгы яисә Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы алдындагы аеруча югары казанышлар өчен бүләкләү очраклары керми.»;

6) 41 статьяның 2 пунктында «Законының» сүзен «Законының 4 статьясының» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 30-ТРЗ

## 756. Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4-5, № 10, № 11; 2005, № 7-8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; № 8 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 29 февраль), «2013 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2016 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да алданрак булмаган вакытта үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 31-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 757. Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» 2011 елның 10 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законынының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «Региональ салымнар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 өлештә «Региональ салымнар буенча» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 32-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 758. Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5), «2013 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2016 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 33-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 759. «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«1 статья**

1. Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен (алга таба – оешмалар-резидентлар) Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын махсус икътисадый зона территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

0 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап биш календарь ел эчендә;

5 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап алтынчы календарь елдан алып унынчы календарь ел тәмамланганчы;

13,5 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап 10 календарь ел үткәннән соң.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары махсус икътисадый зона территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган (эшчәнлеккә тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) һәм эшчәнлекне махсус икътисадый зона территориясеннән читтә гамәлгә ашырганда алынган (эшчәнлеккә тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) оешмалар-резидентлар тарафыннан аерым исәп алып бару шарты белән кулланыла.»;

2) 2 статьяның беренче абзацында «һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 34-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 760. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1(1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш),

2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 6 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:

а) 4 пунктта «аппараты хезмәткәрләрен эшкә кабул итү һәм эштән азат итү» сүзләрен «аппаратын кадрлар белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Җәмәгать судьясы аппаратының кадрлар составын туплау дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарда каралган тәртиптә конкурс нигезендә башкарыла.»;

2) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Җәмәгать судьяларының мәгълүмат ресурсларын берләштерелгән белешмәләр базаларына һәм белешмәләр банкларына кертү чаралары, мәгълүмат системаларының эшләвенә, бердәй принциплар һәм гомуми кагыйдәләр нигезендә эшли торган мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдалануга карата бердәй техник таләпләрне урнаштыру федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 35-ТРЗ

## 761. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8 – 9; 2002, № 2; 2004, № 4 – 5; 2006, № 6 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Федераль законнар нигезендә гражданнарның аерым категорияләре Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетлары акчалары исәбеннән уку өчен дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренә керү сынауларыннан башка, керү сынауларын уңышлы узган очракта конкурстан тыш керү хокукына йә кергәндә өстенлекле хокукка ия була.»;

б) $7^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 16 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда белем алу рәвешләренә бәйсез рәвештә федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон укыту, дистанцион белем бирү технологияләре кулланылырга мөмкин.

Электрон укыту дигәндә белем бирү процессын белешмәләр базаларында булган һәм белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәгълүматны һәм аны эшкәртүне тәэмин итә торган мәгълүмат технологияләрен, техник чараларны

кулланып, шулай ук әлеге мәгълүматны элемтә линияләре буенча тапшыруны, белем бирү процессында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып оештыру аңлашыла.

Дистанцион белем бирү технологияләре дигәндә укучылар белән педагогика хезмәткәрләре, очрашмыйча (бер-берсеннән билгеле бер ераклыкта урнашкан килеш), хезмәттәшлек иткәндә башлыча мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып гамәлгә ашырыла торган белем бирү технологияләре аңлашыла.

Белем бирү программалары бары тик электрон укытуны, дистанцион белем бирү технологияләрен генә кулланып гамәлгә ашырылганда мәгариф учреждениесендә электрон мәгълүмат ресурсларын, электрон белем бирү ресурсларын, мәгълүмат технологияләренең, телекоммуникация технологияләренең, тиешле технологик чараларның күплеген үз эченә алган һәм укучылар тарафыннан, кайда булуларына бәйсез рәвештә, белем бирү программаларын тулы күләмдә үзләштерүне тәэмин итә торган электрон мәгълүмат-мәгариф тирәлеге эшләп торсын өчен шартлар тудырылырга тиеш.»;

3) 22 статьяның 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 30 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә укытылырга тиешле балаларның исәбен алу, муниципаль районнарның, шәһәр округларының билгеле бер территориясен конкрет муниципаль мәгариф учреждениесенә беркетү;»;

5) 32 статьяның 2 пунктындагы «ш» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ш) белем бирү процессының методикаларын һәм белем бирү технологияләрен, шул исәптән электрон укытуны, дистанцион белем бирү технологияләрен куллану һәм камилләштерү.»;

6) 37 статьяга түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

«10. Дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә федераль дәүләт мәгариф стандарты чикләрендә конкурс нигезендә түләүсез урта һөнәри һәм югары һөнәри белем алу Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетлары чаралары исәбеннән уку өчен

гражданнарны кабул итүнең контроль саннары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетлары акчалары исәбеннән уку өчен гражданнарны кабул итүнең контроль саннары дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла торган әзерлек юнәлешләре (белгечлекләр) буенча конкурс нигезендә билгеләнә.

Дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән уку өчен гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын билгеләү тәртибе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, җирле бюджетлар акчалары исәбеннән – җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

7) 45 статьяның 11 пунктындагы беренче абзацында «Тәрбия-хезмәт һәм төзәтү-хезмәт учреждениеләрендәге» сүзләрен «Ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәтүче учреждениеләрдәге» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 4 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Башлангыч һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениеләрендә һәм дәүләт аккредитациясе булган урта һөнәри һәм югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән укучы ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, тулысынча дәүләт тәэминатыннан тыш, түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 11 июне
№ 36-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 762. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 17 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.12, 2.13 статьялар өстәргә:

«2.12 статья. **Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу**

Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен, шулай ук әлеге исәпне алып бару тәртибен гражданнарны исәпкә куюдан йә гражданнарны исәптән төшереп калдырудан законсыз рәвештә баш тартуга китерерлек итеп бозган өчен –

вазыйфаи затларга биш меңнән сигез мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2.13 статья. **Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм исәпне алып бару тәртибен бозу**

Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую тәртибен, шулай ук әлеге исәпне алып бару тәртибен гражданнарны исәпкә куюдан йә гражданнарны исәптән төшереп калдырудан законсыз рәвештә баш тартуга китерерлек итеп бозган өчен –

вазыйфаи затларга биш меңнән сигез мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

2) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.13 статья өстәргә:

«3.13 статья. **Умартачылык өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне бозу**

Умарта кортлары ояларын урнаштырганда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү буенча билгеләнгән таләпләрне бозган өчен –

гражданнарга – ике меңнән дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш меңнән тугыз мең сумга кадәр; юридик затларга ун меңнән унбиш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

3) 7.1 статьяда «2.11,» санын «2.11 – 2.13,» саннарына алмаштырырга, «3.12,» саныннан соң «3.13,» санын өстәргә;

4) 8.1 статьяның икенче өлешендә «2.8,» санынннан соң «2.12, 2.13,» саннарын өстәргә, «3.11, 3.12» саннарын «3.11 – 3.13» саннарына алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 15 июне
№ 37-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 763. Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 105 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«105 статья. **Алиментларны индексацияләү**

Суд карары буенча акчалата суммада түләтелә торган алиментларны индексацияләү Россия Федерациясе Гаилә кодексының 117 статьясы нигезендә башкарыла.»;

2) 116 статьяда:

а) 1 өлештә:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан, яла ягудан һәм хурлаудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хөкем ителүе булган яисә хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булучы яисә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча үзләренә карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);»;

түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

«$9^1$) авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;»;

түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) әлеге статьяның 6 – 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алучы яисә элек уллыкка алган булган һәм үзләренә карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан тыш).»;

б) 2 өлештә «7 һәм 10 пунктларында» сүзләрен «7, 10 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «7 һәм 10 пунктларында» сүзләрен «7, 10 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 6 – 10 өлешләр өстәргә:

«6. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган программа буенча һәм тәртиптә бу затларны психологик-педагогик һәм хокукый яктан әзерләү максатларында гамәлгә ашырыла.

7. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасының эчтәлегенә карата таләпләр һәм Россия Федерациясе территориясендә шундый әзерлекне узу турындагы таныклык рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.

8. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләүне оештыру Татарстан Республикасы бюджетында шул максатлар өчен карала торган акчалар исәбеннән һәм чикләрендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм Россия Федерациясе гражданы булып торучы баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар яисә Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан үзләре даими яши торган дәүләт территориясендә тематикасын исәпкә алып һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасы эчтәлегенә карата әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән таләпләрдә каралганнан кимрәк булмаган күләмдә тиешле әзерлек узуы турында документлар тапшырылырга мөмкин.

10. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар яисә Россия Федерациясе территориясеннән читтә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнары үзләре даими яши торган чит дәүләт территориясендә мондый әзерлекне узмаган очракта, күрсәтелгән әзерлек Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясы нигезендә уздырыла.»;

3) 134 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бары тик балигъ яшьтәге хокуктан файдалануга сәләтле затлар гына опекуннар (попечительләр) булып билгеләнә алалар. Түбәндәгеләр опекуннар (попечительләр) булып билгеләнә алмыйлар:

1) ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән затлар;

2) шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан, яла ягудан һәм хурлаудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен хөкем ителүе булган яисә хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булучы яисә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча үзләренә карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

3) авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;

4) әлеге Кодексның 116 статьясындагы 6 – 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (балаларның якын туганнарыннан, шулай ук балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәүдән читләштерелмәгән затлардан тыш).»;

б) 3 өлештә «сәламәтлеге буенча» сүзләреннән соң «(әлеге Кодексның 116 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты)» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасындагы алтынчы һәм җиденче абзацларыннан, «б» – «г» пунктчаларыннан, 3 пунктының «а» пунктчасындагы алтынчы абзацыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасындагы алтынчы һәм җиденче абзацлары, «б» – «г» пунктчалары, 3 пунктының «а» пунктчасындагы алтынчы абзацы 2012 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 15 июне
№ 38-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 764. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 11; 2005, № 5; 2009, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның бишенче абзацында «иҗтимагый әһәмияткә ия инициативаларны» сүзләреннән соң «, шул исәптән ихтыярый эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча инициативаларны» сүзләрен өстәргә;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ихтыярый эшчәнлекнең оешкан рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру.»;

3) 10 статьяның икенче абзацында «яшь гражданнарның» сүзләреннән соң «һәм ихтыярый эшчәнлекнең» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 15 июне
№ 39-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 765. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 2 маендагы 40-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы $16^1$ пунктын, $91^1$ статьясын, 93 статьясындагы $1^1$ һәм $2^1$ өлешләрен (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9 – 10; 1994, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 2 – 3, № 12; 1996, № 11; 1999, № 6, № 8 (I өлеш); 2000, № 3 (3), № 6 (5), № 12 (10) I өлеш; 2001, № 7 – 8; 2002, № 3 – 4;

2003, № 9 (I өлеш); 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2010, № 3, № 11);

2) «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2005 елның 14 мартындагы 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлешенең өченче һәм дүртенче абзацларын, 2 һәм 3 өлешләрен, 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 3 (I өлеш).

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 22 июне
№ 40-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 766. Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6; 2011, № 8 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 24 декабрь ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 һәм 2 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Сайлау кодексы (алга таба – Кодекс) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын (алга таба шулай ук – Дәүләт Советы депутатлары), Татарстан Республикасы Президентын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлауларны уздыру тәртибен, шу-

лай ук федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары гарантияләрен билгели.

2. Әлеге Кодекс муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлек башлыгын һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларын сайлау тәртибен, әгәр күрсәтелгән вәкиллекле орган, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты закон, муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль сайлауларда турыдан-туры халык тарафыннан сайланса, җайга сала. Муниципаль берәмлекләр башлыкларын сайлаулар һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларын сайлаулар, әгәр әлеге Кодекста муниципаль берәмлекләр башлыкларын сайлауларны җайга салу үзенчәлекләре аерым каралмаган булса, бердәм кагыйдәләр буенча уздырыла.»;

2) 4 статьяда:

а) 1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 18 яшькә җиткән граждан сайлау хокукына ия, ә федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә, әлеге Кодекста билгеләнгән яшькә җиткәч, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы. Тавыш бирү көнендә 18 яшь тулган граждан законда каралган һәм законлы ысуллар белән уздырыла торган башка сайлау гамәлләрендә катнашырга хокуклы.

2. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат итеп 30 яшькә җиткән граждан күрсәтелергә мөмкин. Дәүләт Советы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларына кандидат итеп, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасына кандидат итеп тавыш бирү көнендә 21 яшь тулган граждан күрсәтелергә мөмкин. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатына кандидат итеп тавыш бирү көнендә 18 яшь тулган граждан күрсәтелергә мөмкин.»;

б) 6 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) авыр һәм (яисә) аеруча авыр җинаятьләр кылган өчен кайчан да булса ирегеннән мәхрүм ителүгә хөкем ителүчеләр, бу гамәлләр яңа җинаять законы нигезендә авыр яисә аеруча авыр җинаятьләр булып танылмаган очраклардан тыш;»;

в) 8 өлештә түбәндәге эчтәлекле яңа беренче җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көнгә

икенче срок рәттән Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасын биләп торучы граждан Татарстан Республикасы Президенты булып сайланырга хокуклы түгел.»;

г) 9 өлештә «Дәүләт Советына» сүзләрен «дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

д) 10 өлештә «җирле үзидарә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 5 статьяда «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

4) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «87 статьясындагы 1 өлешендә» сүзләреннән соң «, $104^2$ статьясындагы 1 өлешендә» сүзләрен өстәргә;

5) 10 статьяның 6 өлешендә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

6) 12 статьяның 9 өлешендә «депутатларын» сүзеннән соң «һәм Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен өстәргә;

7) 17 статьяның 15 өлешендә «кабат сайлаулар уздыру турында» сүзләре алдыннан «кабат тавыш бирү яисә» сүзләрен өстәргә;

8) 18 статьяда:

а) 1 өлешнең 5 пунктында «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре),» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 14 өлештә «яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органында» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 27 статьяның 5 өлешендә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

10) 28 статьяның 2 өлешендә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

11) 31 статьяның 1 өлешендә «Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда, муниципаль» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

12) 34 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

13) 42 статьяның 2 өлешендә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган очракларда иренең яисә хатынының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре күләме һәм чыганаклары турында белешмәләрне.»;

14) 43 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43 статья. **Кандидатлар күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзаларын җыю**

1. Кандидатлар күрсәтү, әлеге статьяның 2 һәм 3 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, сайлаучылар тарафыннан имзалар кәгазьләренә үз имзаларын кую юлы белән хупланырга тиеш.

2. Сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчә (әгәр кандидатларны региональ яисә башка структур бүлекчә тарафыннан күрсәтү сәяси партия уставында каралган булса) тарафыннан күрсәтелгән кандидатны теркәү кандидатны күрсәтү турында федераль законда билгеләнгән тәртиптә сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе яисә башка структур бүлекчә тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә сайлаучылар имзаларын җыймыйча гына гамәлгә ашырыла.

3. Сайлау округында сайлаучыларның уртача вәкиллек нормасы ун мең сайлаучыдан артыграк булмаган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарына сайлаулар уздырган-

да, кандидатларны теркәүнең мөрәҗәгатьле тәртибе билгеләнә. Мондый очракта кандидатлар күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзалары җыелмый.

4. Әгәр кандидат күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзалары җыю башкарыла торган булса, кандидатны хуплап тиешле сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның гомуми санынннан 0,5 процент сайлаучылар имзалары җыелырга тиеш, әмма ул 10 имзадан да әзрәк булмаска тиеш. Күпмандатлы сайлау округында һәр кандидатны теркәү өчен кирәкле имзалар саны тиешле сайлау округы территориясендә теркәлгән сайлаучыларның депутат мандатлары санына бүленгән саныннан 0,5 процент тәшкил итә, әмма ул 10 имзадан да әзрәк булмаска тиеш.

5. Вакытыннан алда сайлаулар уздырган очракта, кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле сайлаучылар имзаларының саны икеләтә киметелә, әмма ул 10 имзадан да әзрәк булмаска тиеш.»;

15) 44 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44 статья. **Кандидат күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзаларын җыю һәм имзалар кәгазьләрен тутыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда имзалар кәгазьләрен әзерләү өчен түләнгән көннән башлап имзалар җыелырга мөмкин. Җирле үзидарә органнарына сайлауларда имзалар кандидатны күрсәтү турында комиссиягә хәбәр ителгән көннән соңгы иртәдән башлап җыелырга мөмкин. Имзалар бары тик кандидат күрсәтелгән сайлау округында актив сайлау хокукына ия булган сайлаучылар арасында гына җыелырга мөмкин.

2. Сайлаучылар имзаларын җыю хокукына имзалар җыю вакытына 18 яшь тулган һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылмаган Россия Федерациясе гражданы ия була. Кандидат сайлаучылар имзаларын җыюны башкаручы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзергә мөмкин. Әлеге эш өчен түләү бары тик кандидатның сайлау фонды акчаларыннан гына гамәлгә ашырыла.

3. Сайлаучылар имзаларын җыюга бәйле барлык чыгымнар бары тик кандидатның сайлау фонды акчалары исәбеннән генә гамәлгә ашырыла.

4. Сайлаучылар имзаларын җыю яшәү урыны буенча һәм сайлау алды агитациясен үткәрү һәм имзалар җыю федераль за-

кон белән тыелмаган башка урыннарда гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, барлык милек рәвешендәге оешмаларның, учреждениеләрнең идарә органнары, сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары сайлаучылар имзаларын җыюда катнаша алмыйлар. Имзалар җыю барышында сайлаучыларны үз имзаларын куярга мәҗбүр итү һәм шуның өчен аларны теләсә нинди рәвештә бүләкләү тыела. Эш урыннарында, уку урынында, хезмәт хакы, пенсияләр, пособиеләр, стипендияләр, башка социаль түләүләр бирү процессында һәм урыннарында, шулай ук хәйрия ярдәме күрсәткәндә сайлаучылар имзаларын җыю тыела.

6. Сайлаучылар имзаларын җыю аларны имзалар кәгазьләренә кертү юлы белән гамәлгә ашырыла. Имзалар кәгазьләре тиешле сайлау фонды акчалары исәбеннән әзерләнә. Сайлаучылар имзаларын җыю өчен имзалар кәгазьләре – «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга кушымталар нигезендәге рәвешләр буенча, ә муниципаль берәмлекнең сайланулы органы әгъзаларын күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзаларын җыю өчен әлеге Кодекска 1 нче кушымта нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә һәм тутырыла.

7. Имзалар кәгазендә үзе турында белешмәләр күрсәтелә торган кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган очракта, имзалар кәгазендә өстәмә рәвештә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләр күрсәтелә. Әгәр имзалар кәгазендә үзе турында белешмәләр булган кандидат Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына чыгарга ризалыгы турындагы гаризада әлеге Кодексның 39 статьясындагы 2 өлеше, 40 статьясындагы 3 өлешенең 1 пункты, 41 статьясындагы 2 өлеше, 42 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә үзенең сәяси партиягә йә башка иҗтимагый берләшмәгә каравын һәм шушы сәяси партиядәге йә шушы иҗтимагый берләшмәдәге үз статусын күрсәтсә, бу турыдагы белешмәләр имзалар кәгазендә күрсәтелә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда имзалар кәгазендә имзалар кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү башкарылган махсус сайлау счетының номеры күрсәтелә.

9. Сайлаучы имзалар кәгазендә үз имзасын куя һәм аны кую датасын, шулай ук фамилиясен, исемен, атасының исемен,

туган елын (тавыш бирү көнендә 18 яшь тулса – өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алыштыручы документының сериясен, номерын күрсәтә. Имзалар кәгазендә үз имзасын куйган һәм аны кую датасын күрсәткән сайлаучы турындагы белешмәләр сайлаучы үтенече буенча кандидатны хуплап имзалар җыюны башкаручы зат тарафыннан имзалар кәгазенә кертелергә мөмкин. Мондый белешмәләр бары тик кулдан язып куела, бу очракта карандаш куллану рөхсәт ителми. Сайлаучы имзасын һәм аны кую датасын кулдан яза. Сайлаучы төрле кандидатлар күрсәтүне хуплап имза куярга хокуклы, әмма бер үк кандидатны хуплап бары тик бер генә имза куярга хокуклы.

10. Һәр имзалар кәгазе сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган затның имзасы белән таныкланырга тиеш. Имзалар кәгазен таныклаганда сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алыштыручы документының сериясен, номерын һәм аны бирү датасын, аны биргән органның исемен яисә кодын кулдан язып куя, шулай ук үз имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

11. Кандидатны күрсәтүне (үз-үзен күрсәтүне) хуплап җыелган сайлаучылар имзалары белән һәр имзалар кәгазе кандидат тарафыннан таныкланырга тиеш. Имзалар кәгазен таныклаганда кандидат фамилиясе, исеме һәм атасының исеме янына кулдан имзасын куя һәм аны кую датасын күрсәтә.

12. Кандидатны күрсәтүне хуплап имзалар җыйганда имзалар кәгазен алгы ягыннан һәм арткы ягыннан тутыру рөхсәт ителә. Мондый чакта арткы як имзаларның бердәм номеры белән алгы якның дәвамы булып тора, ә таныклау язмалары имзалар кәгазенең арткы ягында иң соңгы сайлаучының имзасыннан соң кертелә.

13. Сайлаучылар имзаларын җыю тәмамланганнан соң, кандидат сайлаучыларның җыелган имзаларының гомуми санын исәпли һәм сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвеш буенча имзалар җыю йомгаклары турында ике нөсхәдә беркетмә төзи. Беркетмәнең һәр нөсхәсен кандидат үзе имзалый.

14. Имзалар кәгазьләре брошюра итеп тегелгән һәм номерланган килеш сайлау комиссиясенә тапшырыла. Имзалар кәгазьләре белән бергә сайлау комиссиясенә имзалар җыю йомгаклары турында беркетмә ике нөсхәдә кәгазьдә басылган килеш һәм машинадан укыла торган саклагычларда тапшырыла.»;

16) 45 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45 статья. **Кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен сайлау документларын тапшыру**

1. Кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү, кандидатның (кандидатларның) тиешле сайлау округы буенча чыгарга ризалыгы турында гаризасы (гаризалары) һәм әлеге Кодексның 39 – 42 статьяларында күрсәтелгән башка документлары булганда (тапшырылганда), тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Кандидатлар турында белешмәләрнең тулы булмавы ачыкланганда яисә документларны тутыруга карата закон таләпләре үтәлмәгәндә, тиешле сайлау комиссиясе, кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле сайлау комиссиясе утырышы көненә кадәр кимендә өч көннән дә соңгы калмыйча, бу хакта кандидатка, сайлау берләшмәсенә хәбәр итә. Кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле сайлау комиссиясе утырышы көненә кадәр кимендә бер көннән дә соңга калмыйча, кандидат үзе турында белешмәләр булган документларга, ә сайлау берләшмәсе үзе күрсәткән кандидат (кандидатлар) турындагы, шул исәптән кандидатлар исемлеге составында, белешмәләр булган һәм әлеге Кодексның 40 – 42 статьялары нигезендә тапшырылган документларга, шулай ук кандидатны (кандидатларны), кандидатлар исемлеген күрсәтү турында хәбәрнамә бирү өчен һәм аларны теркәү өчен сайлау комиссиясенә тапшырылган башка документларга (сайлаучылар имзалары белән имзалар кәгазьләреннән тыш) аларны закон таләпләренә туры китерү максатларында, шул исәптән аларны тутыруга кагылышлы төгәлләштерүләр һәм өстәмәләр кертергә хокуклы. Кандидат, сайлау берләшмәсе тапшырылган документны бары тик ул закон таләпләрен бозып тутырылган очракта гына алыштырырга хокуклы.

2. Әгәр кандидат күрсәтүне хуплап сайлаучылар имзалары җыю башкарылса, кандидатны теркәү өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) номерлар сугылган һәм папкалар рәвешендә брошюра итеп тегелгән имзалар кәгазьләре. Сайлау комиссиясенә тапшырыла торган имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар имзалары саны кандидатны теркәү өчен кирәкле имзалар санышнан артыграк булырга мөмкин, әмма ул 10 проценттан да күбрәк була алмый. Әгәр кандидатны теркәү өчен 40тан әзрәк имза тапшыру таләп ителсә, сайлаучыларның тапшырыла торган имзалары саны

кандидатны теркәү өчен кирәкле имзалар санынннан артыграк булырга мөмкин, әмма ул дүрт имзадан да күбрәк була алмый;

2) сайлаучылар имзаларын җыю йомгаклары турында беркетмә.

3. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда кандидатны теркәү өчен өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатны хуплау кәгазьләре (алга таба – кандидатны хуплау кәгазьләре). Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органы депутатларының һәм муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының кандидатны хуплау кәгазьләрендәге имзалары саны кандидатны теркәү өчен кирәкле имзалар санынннан артыграк булырга мөмкин, әмма ул 5 проценттан да күбрәк була алмый;

2) кандидатны хуплау кәгазьләрендә үз имзаларын куйган затларның кандидат һәм аны хуплаган затлар турында белешмәләр булган исемлеге.

4. Әгәр кандидат, кандидатлар исемлеге сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән булса, аны теркәү, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар булганда, шушы кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәтү турында федераль законда билгеләнгән тәртиптә, әлеге статьяның 3 өлешендә каралган очрактан тыш, сәяси партия тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Әгәр кандидат муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда күрсәтелгән булса һәм аларны уздырганда әлеге Кодекс белән кандидатларны теркәүнең мөрәҗәгатьле тәртибе билгеләнгән булса, аны теркәү әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен барлык документлар әлеге Кодекста билгеләнгән очракларда кандидат, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле, башка затлар тарафыннан бер үк вакытта тиешле сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар уздырганда тавыш бирү көненә кадәр кимендә 75 көн кала һәм 45 көннән дә соңга калмыйча 18 сәгатькә кадәр тапшырыла яисә җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда кимендә 60 көн кала һәм 40 көннән дә соңга калмыйча 18 сәгатькә кадәр тапшырыла.

7. Кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен документлар кабул иткәндә сайлау комиссиясе аларны тапшырган затка тапшырылган документларның кабул ителүен раслый торган

документ бирә, һәм анда кабул итү датасы һәм вакыты күрсәтелә. Имзалар кәгазьләре (кандидатны хуплау кәгазьләре) тапшырылган очракта, бу документта шулай ук кабул ителгән имзалар кәгазьләренең (кандидатны хуплау кәгазьләренең) саны һәм сайлаучылар имзаларының (кандидатны хуплау кәгазьләрендә куелган имзаларның) алдан белдерелгән саны күрсәтелә. Бу очракта сайлау комиссиясе имзалар кәгазьләре белән һәр папканы (кандидатны хуплап җыелган һәр кәгазьне) үз мөһере (махсус штампы) белән алдан таныклый, тапшырылган имзалар кәгазьләре (кандидатны хуплау кәгазьләре) санының сайлаучылар имзаларын җыю йомгаклары турындагы беркетмәдә күрсәтелгән санга (кандидатны хуплау кәгазьләрендә үз имзаларын куйган затлар исемлегенә) туры килүен тикшерә. Сайлау комиссиясе кандидатка, сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиленә, әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән башка затка ул урнашкан бинага кереп йөрүне чикләргә яисә аңа кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү өчен тапшырыла торган документларны, әгәр бу документлар әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән вакыт узганчы китереп җиткерелгән булса, кабул итүдән баш тартырга хокуклы түгел.»;

17) 46 статьяны түбәндәге статьяда бәян итәргә:

«46 статья. **Кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәткәндә закон таләпләренең үтәлүен тикшерү**

1. Тиешле кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәүне гамәлгә ашыручы сайлау комиссиясе һәр кандидатны, кандидатлар исемлеген күрсәткәндә федераль закон, әлеге Кодекс таләпләренең үтәлүен тикшерә.

2. Имзалар кәгазьләре тапшырылган очракта, сайлау комиссиясе сайлаучылар имзаларын җыю тәртибенең үтәлүен һәм имзалар кәгазьләренең дөрес тутырылуын, имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген тикшерә. Кандидатны хуплау кәгазьләре тапшырылган очракта, сайлау комиссиясе кандидатны хуплау кәгазьләрендә куелган имзаларның дөреслеген һәм кандидатны хуплау кәгазьләрендәге белешмәләрнең аларга туры килүен тикшерә.

3. Сайлау комиссиясе кандидатлар турындагы белешмәләрнең һәм кандидат, сайлау берләшмәсе тарафыннан әлеге Кодекс нигезендә бирелгән башка белешмәләрнең дөреслеген тикшерә.

4. Сайлау комиссиясе әлеге Кодексның 39 – 42 статьялары нигезендә кандидатлар турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү хакындагы күрсәтмә белән тиешле органнарга мөрәҗәгать итә, алар тикшерү нәтиҗәләре турында – 10 көн эчендә, ә кандидатның керемнәре күләме һәм чыганаклары турындагы, шулай ук кандидатның милек хокукындагы мөлкәте (шул исәптән уртак милектәге мөлкәте) турындагы, банклардагы кертемнәре, кыйммәтле кәгазьләре турындагы белешмәләрне 20 көн эчендә хәбәр итәргә тиеш. Әгәр әлеге күрсәтмә тавыш бирү көненә кадәр 10 көн һәм аннан да әзрәк көн кала керсә, тиешле органнар тикшерү нәтиҗәләре турында сайлау комиссиясе билгеләгән вакытка хәбәр итәргә тиеш.

5. Сайлау комиссиясе кандидатларны күрсәткәндә алар турында тапшырылган белешмәләрне сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән күләмдә сайлаучыларга җиткерә.

6. Сайлау комиссиясе кандидатлар тапшырган белешмәләрнең дөрес булмау фактлары ачыклануы турындагы белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрә.

7. Кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтү тәртибенең, сайлаучылар имзаларын җыю һәм имзалар кәгазьләрен тутыру тәртибенең үтәлүен, имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген, кандидатны хуплау кәгазьләрендә куелган имзаларның дөреслеген һәм кандидатны хуплау кәгазьләрендәге белешмәләрнең аларга туры килүен тикшерү өчен сайлау комиссиясе үз карары белән сайлау комиссиясе әгъзаларыннан, аның аппараты хезмәткәрләреннән һәм җәлеп ителгән белгечләрдән эшче төркемнәр төзергә мөмкин. Тикшерүгә түбәнгерәк сайлау комиссияләре әгъзалары, эчке эшләр органнарының, юстиция учреждениеләренең, хәрби комиссариатларның, Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне исәпкә алу органнарының, шулай ук башка дәүләт органнарының белгечләреннән экспертлар җәлеп ителергә мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имзалар кәгазьләрендәге (кандидатны хуплау кәгазьләрендәге) сайлаучылар (муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары) турындагы белешмәләрне һәм аларның имзаларын дөрес түгел дип һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булырга мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имзалар кәгазьләрен (кандидатны хуплау кәгазьләрен) тикшерү

ведомостьларында яисә башка документта язма рәвештә бәян ителә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органына, территориаль бүленеше булмаган шәһәр округының, муниципаль районның башлыгын һәм вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен, сайлаучылар регистрын кертеп, «Сайлаулар» ДАС кулланыла. Территориаль бүленеше булмаган шәһәр округы, җирлек башлыгын һәм вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча, сайлаучылар регистрын кертеп, «Сайлаулар» ДАС кулланылырга мөмкин.

9. Имзалар кәгазьләрендәге белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен сайлау комиссияләре сайлаучыларны, референдумда катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасын, шулай ук «Сайлаулар» ДАСны кулланырга хокуклы. «Сайлаулар» ДАС элемтә каналлары буенча алынган һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисенең электрон санлы имзасы белән имзаланган тикшерү нәтиҗәләре турындагы белешмәләр сайлаучылар имзаларын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булырга мөмкин.

10. Әгәр кандидатны теркәү өчен 200 һәм аннан әзрәк сайлаучылар имзаларын тапшыру таләп ителсә, тапшырылган барлык имзалар һәм имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турында тиешле белешмәләр тикшерелергә тиеш. Әгәр кандидатны теркәү өчен 200дән күбрәк сайлаучылар имзаларын тапшыру таләп ителсә, кандидатны теркәү өчен кирәкле сайлаучылар имзаларының кимендә 20 проценты әлеге статьяның 11, 21 һәм 22 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә тиеш.

11. Башлап тикшерү өчен һәр кандидатны хуплап җыелган имзалар бертигез санда алына. Аралап тикшерү өчен имзалар кәгазьләре очраклы сайлап алу (шобага салу) юлы белән алына. Аралап алу процедурасы тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Аралап алу сайлау комиссиясенең үзендә кандидатка имзалар кәгазьләренең кабул итеп алынуын раслый торган документ тапшырылганнан соң уздырыла. Тикшерү өчен алынган имзалар кәгазьләрендәге барлык сайлаучылар имзалары һәм сайлаучылар турындагы тиешле белешмәләр тикшерелергә тиеш.

12. Сайлаучылар имзаларына тикшерү уздырганда, шул исәптән тикшерү өчен имзаларны аралап алганда, теркәү өчен

кирәкле санда сайлаучылар имзаларын тапшырган кандидат, аның вәкаләтле вәкилләре яисә ышанычлы затлары, теркәү өчен кирәкле санда сайлаучылар имзаларын тапшырган кандидатларны күрсәткән сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре яисә ышанычлы затлары катнашырга хокуклы. Билгеләнгән санда сайлаучылар имзаларын тапшырган кандидатка тиешле тикшерү турында хәбәр ителергә тиеш.

13. Имзалар кәгазьләренә кертелгән, әмма кандидатны күрсәтү инициаторлары тарафыннан төшереп калдырылган (сызылган) сайлаучылар имзалары, әгәр алар имзалар кәгазендә яисә имзалар җыю йомгаклары турындагы беркетмәдә имзалар кәгазьләрен комиссиягә тапшырганчы махсус килештерелгән булса, тикшерелмиләр һәм исәпкә алынмыйлар.

14. Сайлаучылар имзаларын һәм имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турында тиешле белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлаучы имзасы дөрес йә дөрес түгел дип һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

15. Бер зат исеменнән икенче зат куйган имза әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә дөрес түгел дип танылa.

16. Түбәндәге имзалар гамәлгә яраксыз дип таныла:

1) имзалар җыю чорыннан тыш, шул исәптән имзалар кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү көненә кадәр җыелган сайлаучылар имзалары, ә җирле үзидарә органнарына сайлауларда – кандидатны күрсәтү турында сайлау комиссиясенә хәбәр ителгән көннең иртәгесе көненә кадәр җыелган сайлаучылар имзалары;

2) актив сайлау хокукына ия булмаган затларның имзалары;

3) имзалар кәгазендә дөреслеккә туры килми торган белешмәләрне күрсәткән сайлаучылар имзалары. Бу очракта имза Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәүне гамәлгә ашыручы органның рәсми белешмәсе йә әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе булганда гына гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин;

4) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә таләп ителә торган белешмәләрнең берәрсен күрсәтмичә һәм (яисә) имзалар кәгазенә сайлаучы тарафыннан кулдан куелган имзаның датасы күрсәтелмәгән сайлаучылар имзалары;

5) белешмәләре имзалар кәгазенә кулдан язылмыйча яисә карандаш белән кертелгән сайлаучылар имзалары;

6) имзалар кәгазендәге имзаларның куелу даталарына төзәтмәләр керткән сайлаучылар имзалары, әгәр бу төзәтмәләр сайлаучылар белән махсус килештерелмәгән булса, шулай ук имзаларның куелу датасын сайлаучыларның үз куллары белән төзәтелмәгән сайлаучылар имзалары – әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

7) сайлаучылар турындагы тиешле белешмәләрдә төзәтмәләр булган сайлаучылар имзалары, әгәр бу төзәтмәләр сайлаучылар белән яисә сайлаучылар имзаларын җыюны башкаручы затлар белән махсус килештерелмәгән булса;

8) әгәр имзалар кәгазе сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган затның, кандидатның кулдан куелган имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе дөрес булмаса, йә имзалар җыю вакытына 18 яшь тулмыйча сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат имзалар кәгазен таныклаган булса һәм (яисә) бу зат суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган булса, йә имзалар кәгазен таныклау даталарының берәрсе күрсәтелмәгән булса яисә кулдан язылмаган булса, йә сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) имза кую датасында шушы зат, кандидат тарафыннан сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат, кандидат белән махсус килештермичә кертелгән төзәтмәләр булса, йә имзалар кәгазендә сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат турындагы, кандидат турындагы белешмәләр тулысынча күрсәтелмәгән булса яисә дөреслеккә туры килмәсә, йә сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат турындагы белешмәләр аның тарафыннан кулдан язылмаган булса;

9) рәвеше «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга 5, 6, 8 һәм 10 нчы кушымталар таләпләренә, шулай ук әлеге Кодекска 1 нче кушымтага туры килми торган һәм (яисә) әлеге Кодексның 44 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләрендә каралган белешмәләр кертелмәгән һәм (яисә) әлеге Кодексның 44 статьясындагы 6 өлешендә каралган таләпләр үтәлмичә әзерләнгән имзалар кәгазендәге барлык сайлаучылар имзалары;

10) әлеге Кодексның 44 статьясындагы 1 һәм 5 өлешләрендә каралган таләпләрне бозып җыелган сайлаучылар имзалары;

11) имзалар кәгазенә кул куйган сайлаучылар турындагы белешмәләрне алар үзләре һәм шушы имзалар кәгазенә кертелгән сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат шәхсән үзе кертмәгән булса, шул сайлаучыларның имзалары – әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе нигезендә;

12) имзалар кәгазе сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган зат, кандидат тарафыннан таныкланганнан соң кертелгән сайлаучылар имзалары;

13) әгәр сайлаучылар имзаларын җыюны башкарган затның таныклау язмасы кандидатны таныклау язмасыннан соң кертелгән булса, сайлаучыларның имзалар кәгазендәге барлык имзалары.

17. Әгәр имзалар кәгазен тикшергәндә бер үк кандидатны күрсәтүне хуплап бер үк сайлаучының берничә имзасы барлыгы ачыкланса, бер генә имза дөрес дип, калган имзалар гамәлгә яраксыз дип санала.

18. Имзалар кәгазендә әлеге Кодекс таләпләренә туры китерелмичә тутырылган юл (юллар) ачыкланганда, әлеге статьяның 16 өлешендәге 8, 9 һәм 13 пунктларында каралган очраклардан тыш, бары тик шушы юлдагы (юллардагы) имза гына исәпкә алынмый.

19. Имзалар кәгазьләрендәге сайлаучы турындагы белешмәләрдә сүзләрне һәм даталарны шул белешмәләрне бер мәгънәдә аңлауга комачауламый торган итеп кыскарту сайлаучының имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый.

20. Имзалар кәгазен төзегәндә сайлаучы белән яисә имзалар кәгазен таныклаучы зат белән махсус килештерелгән төзәтүләр һәм бозылган урыннар сайлаучының имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый, әгәр аның дөрес булмавы һәм гамәлгә яраксызлыгы әлеге статьяның 16 өлешендәге 8, 9 һәм 13 пунктлары нигезендә билгеләнмәгән булса.

21. Әгәр сайлаучыларның аралап тикшергәндә ачыкланган дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларының саны тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми саныннан 10 процент һәм аннан күбрәк тәшкил итсә, кандидатны теркәү өчен кирәкле сандагы сайлаучылар имзаларыннан тагын 15 процент имза әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә өстәмә рәвештә тикшерелә.

22. Әгәр аралап тикшергәндә сайлаучыларның дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип табылган имзаларының гомуми саны әлеге статьяның 10 һәм 21 өлешләре нигезендә

тикшерелергә тиешле имзаларның гомуми санынннан 10 процент һәм аннан күбрәк тәшкил итсә, имзалар кәгазьләрен тикшерүне дәвам итү туктатыла һәм кандидат теркәлми.

23. Имзалар кәгазьләрен тикшерү тәмамланганнан соң, йомгаклау беркетмәсе төзелә, анда сайлаучыларның алдан белдерелгән имзалары саны, тапшырылган имзалары саны һәм тикшерелгән имзалары саны, шулай ук дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылган имзалар саны һәм аларны шундыйлар дип тануның нигезләре (сәбәпләре) күрсәтелә.

24. Беркетмәнең күчермәсе, кандидатны теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле комиссия утырышына кадәр кимендә ике тәүлектән дә соңга калмыйча, әлеге кандидатка тапшырыла. Әгәр тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлаучыларның дөрес имзалары саны кандидатны теркәү өчен җитәрлек булмавы ачыкланса йә дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның саны тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми санынннан 10 процент һәм аннан күбрәк булса, кандидат комиссиядә йомгаклау беркетмәсенең күчермәсе белән бергә имзалар кәгазьләрен тикшерү ведомостьларының таныкланган күчермәләрен алырга хокуклы, аларда сайлаучыларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану нигезләре (сәбәпләре), шундый имзалар булган папкаларның, имзалар кәгазенең номерлары һәм имзалар кәгазендәге юл күрсәтелә, шулай ук кандидат тиешле имзаларны дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була торган рәсми документларның күчермәләрен алырга хокуклы.

25. Йомгаклау беркетмәсе комиссиянең кандидатны теркәү турындагы йә кандидатны теркәүдән баш тарту турындагы карарына өстәлеп куела. Комиссия тарафыннан мондый карар кабул ителгәннән соң, имзалар кәгазен кабат тикшерү бары тик суд тарафыннан яисә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 76 статьясындагы 6 пункты нигезендә комиссия тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

18) 47 статьяда:

а) 6 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм (яисә) муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының Татарстан Республи-

касы Президенты вазыйфасына кандидатны теркәү өчен тапшырылган дөрес имзаларының саны җитәрлек булмау;»;

10 пунктта «67 статьяда билгеләнгән» сүзләрен «89, $104^6$ һәм 106 статьяларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктта «67 статьяда билгеләнгән» сүзләрен «89, $104^6$ һәм 106 статьяларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

б) 7 өлештә:

5 һәм 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

8 пунктта «67 статьяда билгеләнгән» сүзләрен «89, $104^6$ һәм 106 статьяларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «67 статьяда билгеләнгән» сүзләрен «89, $104^6$ һәм 106 статьяларында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

19) 52 статьяның 1 өлешендәге өченче җөмләсендә «Кандидатларның республика исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат, кандидатларның республика исемлеген, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатны күрсәткән сайлау берләшмәсе» сүзләренә алмаштырырга;

20) 57 статьяның 1 өлешендә «Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны һәм муниципаль сайлауларны» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларны» сүзләренә алмаштырырга;

21) 60 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«60 статья. **Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында сайлау алды агитациясен үткәрүнең гомуми шартлары**

1. Дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре теркәлгән кандидатларга, кандидатлар исемлекләрен теркәгән сайлау берләшмәләренә сайлау алды агитациясен үткәрү өчен, шул исәптән федераль законда, әлеге Кодекста билгеләнгән тәртиптә сайлаучыларга сайлау алды программаларын тәкъдим итү өчен, бертигез шартлар тәэмин итәргә тиеш. Күрсәтелгән телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакыты һәм күрсәтелгән вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданы теркәлгән кандидатларга, кандидатлар исемлекләрен теркәгән сайлау берләшмәләренә түләүле бирелә, ә федераль законда, әлеге Кодекста каралган очракларда һәм

тәртиптә түләүсез дә (түләүсез эфир вакыты, түләүсез матбугат мәйданы) бирелергә мөмкин.

2. Теркәлгән кандидат, сайлау берләшмәсе үзләренә бирелгән эфир вакытыннан, матбугат мәйданыннан башка теркәлгән кандидатлар, башка сайлау берләшмәләре өчен сайлау алды агитациясе алып бару өчен файдаланырга хокуклы түгел. Сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән теркәлгән кандидат үзенә бирелгән эфир вакытыннан, матбугат мәйданыннан үзен күрсәткән сайлау берләшмәсе өчен, шулай ук әлеге сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән башка кандидатлар өчен шул ук сайлауларда сайлау алды агитациясе алып бару өчен файдаланырга хокуклы. Кандидатларны, кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсе үзенә бирелгән эфир вакытыннан, матбугат мәйданыннан үзе күрсәткән теләсә кайсы кандидат өчен шул ук сайлауларда сайлау алды агитациясен уздыру өчен файдаланырга хокуклы.

3. Бер үк территориядә бер үк вакытта берничә сайлау кампаниясе уздырылган һәм әлеге кампанияләрдә телерадиотапшырулар оешмаларының каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында агитация алып бару чорлары бер үк вакытка туры килгән очракта, түләүсез эфир вакытының һәм түләүсез матбугат мәйданының гомуми күләме телерадиотапшырулар оешмасының, вакытлы матбугат басмасы редакциясенең шуңа ризалыгыннан башка арттырылмый.

4. Дәүләткә карамаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм сайлау кампаниясе башланырга кимендә бер ел кала теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы дәүләткә карамаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, шулай ук сайлау берләшмәләре (шул исәптән аларның структур бүлекчәләре) тарафыннан гамәлгә куелган һәм сайлау кампаниясе башланырга бер елдан да кимрәк вакыт калгач теркәлгән дәүләткә карамаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә тиешле массакүләм матбугат чараларында эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуклы. Дәүләткә карамаган бүтән телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләткә карамаган бүтән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре теркәлгән кандидатларга, сайлау берләшмәләренә эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуклы түгел.

5. Дәүләткә карамаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләткә карамаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, мат-

бугат мәйданы өчен түләү шартлары барлык теркәлгән кандидатлар, сайлау берләшмәләре өчен бертөрле булырга тиеш. Бу таләп кандидатлар, сайлау берләшмәләре тарафыннан гамәлгә куелган дәүләткә карамаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә кагылмый.

6. Эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлары турындагы белешмәләр, сайлаулар билгеләү турындагы карар рәсми бастырып чыгарылган (игълан ителгән) көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча, тиешле телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр һәм сайлау алды агитациясе алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүгә әзер булу турындагы хәбәрнамә шушы ук срок эчендә сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш.

7. Дәүләткә карамаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләткә карамаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, атнага бер тапкырдан да сирәгрәк чыга торган дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, махсуслаштырылган телерадиотапшырулар оешмалары һәм махсуслаштырылган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре (мәдәни-агарту, балалар, техник, фәнни һәм башка), ә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда шулай ук муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре дә сайлау алды агитациясе алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүдән баш тартырга хокуклы. Тиешле комиссиягә әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән хәбәрнамәне шушы өлештә билгеләнгән срокларда тапшырмау шул рәвешле баш тарту дип санала.

8. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар сайлау алды агитациясе алып бару өчен бирелгән эфир вакытының һәм матбугат мәйданының күләмнәрен һәм бәясен тиешле комиссия тарафыннан билгеләнгән рәвешләрдә һәм тәртиптә аерым исәпкә алып барырга һәм шундый исәпкә алу күрсәткечләрен, тавыш биргән көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча, шул комиссиягә тапшырырга тиеш.

9. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар түләүсез һәм түләүле эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирү турындагы әлеге статьяның 8 өлешендә

күрсәтелгән исәпкә алу документларын тавыш биргән көннән алып кимендә өч ел дәвамында сакларга тиеш.

10. Дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмаларының һәм дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләренең сайлау алды агитациясе алып бару өчен түләүсез эфир вакыты һәм түләүсез матбугат мәйданы бирүгә бәйле чыгымнары әлеге оешмаларның һәм редакцияләрнең эшчәнлек нәтиҗәләренә кертелә.

11. Сайлау алды агитациясе алып бару өчен телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакытын, вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданын бирү эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгәнче телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе белән кандидат, сайлау берләшмәсе арасында язма рәвештә төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Бер үк территориядә бер үк вакытта берничә сайлау кампаниясе уздырылган очракта һәм әлеге кампанияләрдә телерадиотапшырулар оешмалары каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында сайлау алды агитациясе алып бару чорлары туры килгән очракта, төрле сайлауларда берничә сайлау округыннан бер үк вакытта күрсәтелгән теркәлгән кандидат дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмаларында һәм вакытлы матбугат басмаларында түләүсез эфир вакытын һәм түләүсез матбугат мәйданын югарырак дәрәҗәдәге сайлауларда аңа бирелергә тиешле күләменнән арттырмыйча алырга хокуклы.

13. Моңа кадәр узган якындагы тиешле сайлауларда тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 3 проценттан да кимрәк тавышын җыйган һәм депутат мандатларын бүлешүгә кертелмәгән кандидатлар исемлеген күрсәткән йә сайланмаган һәм тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 3 проценттан да кимрәк тавышын җыйган кандидатны күрсәткән сайлау берләшмәсе түләүсез эфир вакытыннан, түләүсез матбугат мәйданыннан файдаланырга хокуклы түгел. Мондый сайлау берләшмәсе түләүсез эфир вакытының, түләүсез матбугат мәйданының гомуми күләменнән үзенә тиешле өлешне яисә аның бер өлешен тиешле шартнамә нигезендә түләп алырга хокуклы, ул түләүнең күләме сайлау алды агитациясе алып бару өчен дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан әлеге Кодексның 61 статьясындагы 9 өлеше һәм 62 статьясын-

дагы 5 өлеше нигезендә резервлана торган эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләү күләменнән арта алмый. Әлеге өлештә каралган шартнамә нигезендә бирелә торган эфир вакытын һәм матбугат мәйданын бүлү әлеге Кодекста эфир вакытын һәм матбугат мәйданын бүлү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырылырга тиеш.

14. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына сайлауларда кандидатларны һәм (яисә) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенә түләүсез эфир вакытын, түләүсез матбугат мәйданын бирүдән баш тарту мөмкин түгел, әгәр моңа кадәр узган якындагы сайлауларда:

1) шушы сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның әлеге Кодексның шушы статьясының 13 өлеше нигезендә ачыклана торган, әлеге Кодекста билгеләнгәннән дә кимрәк булмаган санда тавышлар җыйса;

2) сайлау берләшмәсе кандидатларны бары тик бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча гына күрсәткән булса.»;

22) 61 статьяда:

а) 1 өлештә «60 статьясындагы 11 өлешендә» сүзләрен «60 статьясындагы 13 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

23) 63 статьяда:

а) 3 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

24) 66 статьяда:

а) 4 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 8 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 11 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

25) 67 статьяда:

а) 5 һәм 6 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Кандидатларның, сайлау берләшмәләренең сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатның, сайлау берләшмәсенең үз акчалары;

2) кандидатка үзен күрсәткән сайлау берләшмәсе бүлеп биргән акчалар;

3) гражданнарның ирекле иганәләре;

4) юридик затларның ирекле иганәләре.

6. Сайлау фондларына күчерелә торган кандидатның, сайлау берләшмәсенең үз акчаларының, кандидатка үзен күрсәткән сайлау берләшмәсе бүлеп биргән акчаларның, гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләренең иң чик күләмнәре, шулай ук сайлау фондларының акчаларын тотуның иң чик күләмнәре әлеге Кодекс белән билгеләнә.»;

б) 7 – 13 өлешләрне үз көчен югалткан дип танырга;

26) 68 статьяның 3 өлешендә «67 статьясында каралган» сүзләрен «89, $104^6$ һәм 106 статьяларында каралган» сүзләренә алмаштырырга;

27) 69 статьяның 3 өлешендә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

28) 70 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктында «, кандидатлар исемлеген» сүзләрен төшереп калдырырга;

29) 73 статьяның 3 өлешендәге 5 пунктында «мөлкәте турында белешмәләр» сүзләреннән соң «, ә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда каралган очракларда – ире яисә хатынының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре һәм мөлкәте турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

30) 74 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Кабат тавыш бирү уздырылган очракта, сайлаучы сайлауларны оештыручы комиссия кабат тавыш бирү билгеләгән көннән алып кабат тавыш бирү көненнән алдагы көнгә кадәр тиешле участок комиссиясендә өзмә талоннан башка гына бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары алырга хокуклы.»;

б) 2 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда һәм муниципаль сайлауларда» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлешнең икенче җөмләсендә «Әлеге Кодексның 128[1] статьясындагы 1 өлеше» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон һәм әлеге Кодекс» сүзләренә алмаштырырга;

г) 13 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Әгәр сайлауларда кабат тавыш бирү каралган булса, файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының өзмә талоннары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары кабат тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Кабат тавыш бирү уздырылмаган очракта, файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары, сайлаулар нәтиҗәләре рәсми бастырып чыгарылганнан соң өченче көненнән дә соңга калмыйча, сайлау комиссиясе тарафыннан юкка чыгарыла. Файдаланылмаган бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары һәм өзмә талоннарны юкка чыгару турындагы белешмәләр, аларның санын, шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларының номерларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвеш буенча төзелгән актка тиешле сайлау комиссиясе тарафыннан кертелә.»;

31) 75 статьяда:

а) 3 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бердәм сайлау округы буенча бюллетеньнең рәвеше һәм тексты, бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча бюллетень рәвеше, бюллетеньнәр саны, шулай ук бюллетеньнәр әзерләүне тикшереп тору тәртибе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларда тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча бюллетень тексты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда тавыш бирү көненә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча һәм җирле үзидарә органнарына сайлауларда тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча, тиешле округ комиссиясе тарафыннан раслана. Бюллетень тексты аның бары тик бер ягында гына урнаштырылырга тиеш. Вәкиллекле органнар депутатларын сайлауларны бердәм сайлау округы һәм бермандатлы һәм (яисә) күпмандатлы сайлау округлары буенча бер үк вакытта уздырганда бердәм сайлау округы һәм бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округы буенча сайлау бюллетеньнәре рәвешләре буенча аерылып торырга тиеш.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Кабат тавыш бирү уздырылган очракта, бюллетень тексты, бюллетеньнәр саны сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан кабат тавыш бирүне уздыру турындагы карар кабул итү белән бер үк вакытта раслана. Бу чакта бюллетеньгә беренче булып сайлаучыларның иң күп тавышларын алган теркәлгән кандидатның фамилиясе урнаштырыла.»;

г) 21 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Тавыш бирү көненә кадәр ун көннән дә кимрәк кала кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен теркәү турындагы, бюллетеньнәр әзерләгәннән соң киткән кандидат урынына кабат тавыш бирү уздырганда шуннан соңгы теркәлгән кандидатка шушы урынны тапшыру турындагы карарлар кабул ителгән очракта, кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәгән комиссия әзерләнгән бюллетеньнәргә шушы теркәлгән кандидат, кандидатлар исемлеге турындагы күрсәткечләрне кулдан яисә техник чаралар кулланып кертү хакында карар кабул итәргә хокуклы.»;

32) 76 статьяда:

а) 1 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга, «Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда һәм муниципаль сайлауларда» сүзләрен «Татарстан

Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына сайлауларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешкә «20 көннән дә соңга калмыйча,» сүзләреннән соң «ә кабат тавыш бирү уздырганда – тавыш бирү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча,» сүзләрен өстәргә;

33) 78 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле өченче җөмлә өстәргә: «Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздырганда участок комиссиясе тиешле сайлау участогында тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи.»;

34) 79 статьяда:

а) 2 өлештә «федераль дәүләт хакимияте органнарына,» сүзләреннән соң «аннары – Татарстан Республикасы Президентын,» сүзләрен өстәргә;

б) 32 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

35) 81 статьяда:

а) 2 өлештә «97 статьясындагы 2 өлешендә,» сүзләреннән соң «$104^{12}$ статьясындагы 3 өлешендә,» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлештә «Дәүләт Советы депутатларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

36) 89 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 – 6 өлешләр өстәргә:

«3. Дәүләт Советы депутатлыгына кандидатларның сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 50 процентыннан артыграк була алмый;

2) кандидатка үзен күрсәткән сайлау берләшмәсе бүлеп биргән акчалар, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 50 процентыннан артыграк була алмый;

3) гражданнарның ирекле иганәләре, аларның күләме һәр граждан өчен кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 1 процентыннан артыграк була алмый;

4) юридик затларның ирекле иганәләре, аларның күләме һәр юридик зат өчен кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 40 процентыннан артыграк була алмый.

4. Дәүләт Советы депутатлыгына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 3 миллион сумнан артыграк була алмый.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренең сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) сайлау берләшмәсенең үз акчалары, аларның гомуми күләме сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 50 процентыннан артыграк була алмый;

2) гражданнарның ирекле иганәләре, аларның күләме һәр граждан өчен сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 0,1 процентыннан артыграк була алмый;

3) юридик затларның ирекле иганәләре, аларның күләме һәр юридик зат өчен сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 4 процентыннан артыграк була алмый.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларда кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 30 миллион сумнан артыграк була алмый.»;

37) 95 статьяның 4 өлешендә:

а) 3 пунктта «аларның санын» сүзләреннән соң «һәм номерларын» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

38) 96 статьяның 4 өлешендәге 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

39) Махсус өлешкә түбәндәге эчтәлекле $I^1$ кисәк өстәргә:

«I[1] КИСӘК
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫН САЙЛАУЛАР

## 16[1] бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

### 104[1] статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар**

Татарстан Республикасы Президенты бердәм республика сайлау округы буенча сайлана. Республика сайлау округына Татарстан Республикасының бөтен территориясе керә.

### 104[2] статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү**

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә. Сайлауларны билгеләү турындагы карар тавыш бирү көненнән 100 көннән дә иртәрәк һәм 90 көннән дә соңрак кабул ителмәскә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Президенты үз вәкаләтләрен башкаруны конституциячел срок узганчы ук Татарстан Республикасы Конституциясендә, федераль законда каралган очракларда һәм тәртиптә туктатканда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, вәкаләтләр болай туктатылган көннән 14 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын вакытыннан алда сайлаулар билгели.

3. Әгәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әлеге статьяда каралган срокларда билгеләмәсә, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы булмаган очракта, сайлаулар, тавыш бирү көненә кадәр 80 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

### 104[3] статья. **Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатлар күрсәтү хокукы**

1. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатлар (алга таба шулай ук әлеге бүлектә – кандидатлар) сәяси партияләр тарафыннан тәкъдим ителә.

2. Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесе) вазыйфасын биләгән һәм шул вазыйфасыннан Россия Федерациясе Президенты тарафыннан җибәрелгән граждан Россия Федерациясе Президентының аны вазыйфасыннан җибәрү турындагы указы үз көченә кергән көннән һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар билгеләнгән көнгә кадәр исәпләнә торган ике ел эчендә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат итеп күрсәтелә алмый.

3. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасын биләгән һәм үз теләге белән отставкага китүгә бәйле рәвештә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан аңа ышанычсызлык белдерүгә бәйле рәвештә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан граждан шушы хәлләргә бәйле рәвештә билгеләнгән сайлауларда кандидат итеп күрсәтелә алмый, моңа федераль законда каралган очрак керми.

104[4] статья. **Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатлар күрсәтүне хуплау**

1. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат күрсәтүне муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм (яисә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының әлеге депутатларның Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турында карар кабул ителгән көнгә шушы муниципаль берәмлекләрнең уставларында каралган гомуми санынннан һәм муниципаль сайлауларда сайланган һәм әлеге карарны кабул итү көненә шушы муниципаль берәмлекләрнең эшләп килүче башлыклары саныннан 5 проценты хупларга тиеш. Бу чакта муниципаль район составына керүче җирлекләр башлыкларыннан һәм әлеге җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан торган муниципаль районның вәкиллекле органы депутатлары бер мәртәбә генә исәпкә алына.

2. Кандидатны хуплаган затлар арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатлары һәм (яисә) муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларының Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турында карар

кабул ителгән көнгә шушы муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының уставларында каралган гомуми санынннан һәм әлеге карарны кабул итү көненә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының муниципаль сайлауларда сайланган һәм эшләп килүче башлыклары санынннан 5 процент булырга тиеш. Бу чакта кандидат Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының кимендә дүрттән өчендә әлеге затлар тарафыннан хупланырга тиеш.

3. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары булмаган очракта, кандидат әлеге муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары тарафыннан хуплана.

4. Әгәр Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турындагы карар кабул ителгән көнгә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы оештырылмаган һәм (яисә) муниципаль берәмлек башлыгы сайланмаган булса, шул исәптән тиешле вәкаләтләр вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатны хуплау өчен кирәкле затлар санын билгеләгәндә мондый вәкиллекле орган депутатларының муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнгән саны һәм (яисә) шушы муниципаль берәмлек башлыгы исәпкә алынмый.

5. Кандидатны әлеге статьяның 1, 2 һәм 4 өлешләре нигезендә күрсәтүне хуплау өчен кирәкле затлар саны (абсолют белдерелешендә), шулай ук әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән муниципаль берәмлекләр саны (абсолют белдерелешендә) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләгән көннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм халыкка җиткерелә.

6. Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының имзаларын җыю кандидатны хуплау кәгазьләрендә аларны куеп чыгу юлы белән гамәлгә ашырыла. Әлеге имзалар Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат күрсәткән көннән җыелырга мөмкин.

7. Кандидатны хуплау кәгазендә кандидатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, туу датасы, төп эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаган очракта – шөгыльләренең төре); кандидатның даими яшәү урынындагы Россия Федерациясе субъектының, районның, шәһәрнең, бүтән торак пунктының исеме; кандидатны күрсәтү

турындагы белешмәләр (сәяси партия яисә аның региональ бүлекчәсе тарафыннан күрсәтелгән (сәяси партиянең яисә аның региональ бүлекчәсенең исемен күрсәтеп); кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган очракта – кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләр күрсәтелә. Кандидатны хуплау кәгазендә шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының имза салучы депутатының яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган имза салучы башлыгының фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм туу датасы; депутаты имза салучы зат булган муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган имза салучы башлыгы вазыйфасы исеме; муниципаль берәмлек исеме күрсәтелә. Кандидатны хуплау кәгазьләре әлеге Кодексның 10 нчы кушымтасы нигезендәге рәвеш буенча әзерләнә һәм рәсмиләштерелә.

8. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмаларның идарә органнарының, учреждениеләрнең, сайлау комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының имзалар җыюда катнашулары, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларын кандидатны хуплап имзалар җыю процессында катнашуга мәҗбүр итү һәм салган имзалары өчен аларны бүләкләү рөхсәт ителми.

9. Муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының имзаларын җыю хокукына имзалар җыю көненә 18 яшькә җиткән һәм суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип танылмаган Россия Федерациясе гражданы ия була. Кандидат имзалар җыючы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзергә мөмкин.

10. Кандидатны хуплау кәгазьләрен әзерләүгә һәм сайлаучылар имзаларын җыюга бәйле барлык чыгымнар бары тик кандидатның сайлау фонды аша гына гамәлгә ашырыла.

11. Кандидат, аның яшәү урыны турындагы күрсәткечләр, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының имза салучы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган имза салучы башлыгы турындагы күрсәткечләр, депутаты имза салучы зат булган муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы исеме яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган имза салучы башлыгы вазыйфасы исеме кандидатны хуплау кәгазенә машин-

када басып яисә кулдан язып кертелергә мөмкин. Бу чакта карандашлар куллану рөхсәт ителми. Имзасын, аны кую датасын һәм вакытын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы үз кулы белән яза. Кандидатны хуплау кәгазендәге имзаның хаклыгы нотариаль таныкланырга тиеш. Законда каралган очракларда кандидатны хуплау кәгазендәге имзалар җирле үзидарә органының нотариаль гамәлләр башкарырга вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан таныкланырга мөмкин. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы тарафыннан үз имзасын кире алу рөхсәт ителми.

12. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы теләсә кайсы сәяси партия күрсәткән бары тик бер генә кандидатны күрсәтүне хуплап имза салырга хокуклы. Муниципаль районның муниципаль район составына керүче җирлекләр башлыкларыннан һәм әлеге җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан торган вәкиллекле органының депутаты кандидатны бары тик муниципаль районның вәкиллекле органы депутаты буларак кына хупларга мөмкин.

13. Кандидатны күрсәтүне хуплап муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының, муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының имзаларын җыйганда, кандидатны хуплау кәгазенең бары тик алгы ягын гына тутыру рөхсәт ителә. Имзаның хаклыгын таныклау турында нотариусның (Россия Федерациясе законнары нигезендә нотариаль гамәлләр кылырга вәкаләтле вазыйфаи затның) таныклау язмасын кую өчен кандидатны хуплау кәгазенең алгы ягы да, арткы ягы да кулланылырга мөмкин.

14. Кандидатны күрсәтүне хуплап имзалар җыю тәмамланганнан соң, кандидат һәм аны хуплаган затлар турында әлеге статьяның 7 өлешендә каралган белешмәләре булган кандидатны хуплау кәгазьләренә үз имзаларын салган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары исемлеге Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгеләнгән рәвеш буенча төзелә. Әлеге исемлеккә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат имза сала.

15. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла торган кандидатны хуплау кәгазьләре бер яисә бер-

ничә папкага брошюра итеп тупланырга, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары имзаларын җыю уздырылган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча аерым-аерым әзерләнергә һәм аларга номерлар куелырга тиеш. Кандидатны хуплау кәгазьләре белән бергә кандидатны хуплаган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыклары исемлеге дә кәгазь саклагычта бер нөсхәдә яисә машинадан укырлык итеп тапшырыла.

104[5] статья. **Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатларны теркәү**

1. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатларны теркәү әлеге Кодексның 45 статьясында күрсәтелгән документлар һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының кандидатны күрсәтүне хуплап җыелган имзаларының кирәкле саны булганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәр кандидатны күрсәтүнең федераль закон, әлеге Кодекс белән каралган тәртибе үтәлешен, кандидат турындагы белешмәләрнең һәм кандидат тарафыннан тапшырылган бүтән белешмәләрнең дөреслеген, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының кандидатны хуплау кәгазьләрендә кандидатны хуплап салынган имзаларының һәм кандидатны хуплау кәгазьләрендә аларга туры килүче белешмәләрнең дөреслеген тикшерә.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны хуплау кәгазьләрендә имзаларын салган муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының исемлеге тапшырылган көннән өч көн эчендә әлеге исемлекне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үз сайтында урнаштыра.

4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәү өчен документлар тапшырылган көннән кандидатны

хуплау кәгазьләрендә салынган имзаларның дөреслеген тикшерә. Теркәлү өчен кандидат тарафыннан тапшырылган барлык имзалар һәм кандидатны хуплау кәгазьләрендәге аларга туры килә торган белешмәләр тикшерелергә тиеш.

5. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, имзаларның дөреслегенә шик туган очракта, шул исәптән кандидатны хуплау кәгазен рәсмиләштерүдәге җитешсезлекләргә бәйле рәвештә имзасының дөреслегенә шик туган затны сораштыру уздырырга хокуклы. Әлеге затның Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылган язма гаризасы тикшерү срогы тәмамланганчы аның кандидатны хуплау кәгазендәге имзасының дөреслеген тану өчен нигез булып тора. Әгәр имзаларны тикшергәндә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы бер үк кандидатны хуплап берничә имза салган булса, бер генә имза исәпкә алына. Әгәр имзаларны тикшергәндә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы бердән артык кандидатны хуплаган булса, вакыты буенча иң беренче салынган имза исәпкә алына.

6. Кандидатны хуплау кәгазендә салынган имза түбәндәге очракларда дөрес түгел дип таныла, әгәр:

1) имза салу мизгеленә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы булмаган зат тарафыннан имза салынса, шул исәптән вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга бәйле рәвештә дә. Имза шушы нигез буенча әлеге Кодексның 46 статьясындагы 15 өлешендә билгеләнгән тәртиптә дөрес түгел дип таныла;

2) имза әлеге Кодексның $104^4$ статьясының 7 өлешен бозып җыелса;

3) имза әлеге Кодексның $104^4$ статьясының 6 өлешен бозып җыелса һәм бу җитешсезлек әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән тәртиптә төзәтелмәсә;

4) имза кандидатны күрсәткәнче үк йә имзаның хаклыгын таныклау турында нотариусның (Россия Федерациясе законнары нигезендә нотариаль гамәлләр кылырга вәкаләтле вазыйфаи затның) таныклау язмасы куелганнан соң салынса;

5) кандидатны хуплау кәгазендә кандидат, кандидатны хуплау кәгазендә имза салган муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы турындагы белешмәләр дөреслеккә

туры килмәсә һәм бу җитешсезлек әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән тәртиптә бетерелмәсә;

6) кандидат яисә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыгы турындагы белешмәләрдә йә имза салу датасында һәм (яисә) вакытында төзәтүләр булса һәм бу җитешсезлек әлеге статьяның 5 өлешендә билгеләнгән тәртиптә бетерелмәсә.

7. Кандидатны хуплау кәгазьләрен тикшерү тәмамланганнан соң йомгаклау беркетмәсе төзелә, анда алдан белдерелгән имзалар саны, тапшырылган имзалар саны һәм дөрес түгел дип танылган имзалар саны, аларны шундый дип тану нигезләре (сәбәпләре) күрсәтелә.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, кандидатны теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле утырыш көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, кандидатка тикшерү нәтиҗәләре хакында хәбәр итә һәм аңа йомгаклау беркетмәсенең күчермәсен җибәрә. Әгәр тикшерү нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм муниципаль берәмлекләрнең муниципаль сайлауларда сайланган башлыкларының дөрес имзалары саны кандидатны теркәү өчен җитәрлек булмаса, кандидат Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясендә, беркетмәнең күчермәсе белән бергә, папканың, кандидатны хуплау кәгазенең номеры күрсәтелгән килеш, имзаларны дөрес түгел дип тану нигезләре (сәбәпләре) аталган тикшерү ведомостен, шулай ук тиешле имзаларны дөрес түгел дип тану өчен нигез булган рәсми документларның күчермәләрен алырга хокуклы.

9. Йомгаклау беркетмәсе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кандидатны теркәү турындагы йә кандидатны теркәүдән баш тарту турындагы карарына кушып куела. Кандидатны хуплау кәгазьләрен кабат тикшерү комиссия әлеге карарны кабул иткәннән соң «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 76 статьясындагы 6 пункты нигезендә бары тик суд яисә комиссия тарафыннан гына башкарылырга мөмкин.

10. Кандидат турында ялган белешмәләр барлыгы яисә документларны рәсмиләштерүгә карата закон таләпләрен үтәмәү ачыкланганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе утырышы көненә

кадәр өч көннән дә соңга калмыйча бу хакта кандидатка хәбәр итә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең кандидатны теркәү турындагы мәсьәлә каралырга тиешле утырышы көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча, кандидат үзе турындагы белешмәләр булган документларга, ә сәяси партия үзләре күрсәткән кандидат турында белешмәләр булган һәм әлеге Кодексның 42 статьясы нигезендә тәкъдим ителгән документларга, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә кандидатны күрсәтү турында хәбәр итү һәм аны теркәү өчен тапшырылган башка документларга күрсәтелгән документларны закон таләпләренә, шул исәптән рәсмиләштерүгә карата, туры китерү максатларында төгәлләштерүләр һәм өстәмәләр кертергә хокуклы.

Әгәр муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының, муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлек башлыгының имзасы кандидатны хуплау кәгазендә әлеге статьяның 6 өлешендәге 3 – 6 пунктлары нигезендә дөрес түгел дип танылса, кандидат әлеге хуплау кәгазен шул ук вәкиллекле орган депутаты, муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль берәмлек башлыгы имзасы белән шушы Кодекс нигезендә рәсмиләштерелгән башка хуплау кәгазе белән алмаштырырга хокуклы. Кандидат башка тапшырылган документны бары тик ул «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән очракта гына алмаштырырга хокуклы.

### $104^6$ статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны финанслау**

1. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру чыгымнары Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

2. Кандидатлар үз сайлау кампаниясен финанслау өчен үз сайлау фондларын төзергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатларның сайлау фондлары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең

50 процентыннан, ә кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатлар өчен – 75 процентыннан артыграк була алмый;

2) кандидатка үзен чыгарган сәяси партия бүлеп биргән акчалар, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 50 процентыннан артыграк була алмый;

3) гражданнарның ирекле иганәләре, аларның күләме һәр граждан өчен кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 0,1 процентыннан артыграк була алмый;

4) юридик затларның ирекле иганәләре, аларның күләме һәр юридик зат өчен кандидатның сайлау фонды акчаларыннан барлык чыгымнарының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән иң чик күләменең 4 процентыннан артыграк була алмый.

4. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 60 миллион сумнан, ә кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатлар өчен – 72 миллион сумнан артыграк була алмый.

## $16^2$ бүлек. **Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау комиссияләре**

### $104^7$ статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау комиссияләре системасы һәм статусы**

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны түбәндәге сайлау комиссияләре гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе;

территориаль комиссияләр;

участок комиссияләре.

### $104^8$ статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда:

1) Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау комиссияләренең эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

2) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда гражданнарның сайлау хокуклары үтәлешен тикшереп тора, әлеге Кодексның бер генә төрле кулланылышын тәэмин итә;

3) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр һәм бүтән норматив хокукый актлар бастырып чыгара;

4) түбәнгерәк сайлау комиссияләренә хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

5) кандидатларны терки;

6) кандидатларның ышанычлы затларын, финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен терки;

7) теркәлгән кандидатларга, аларның ышанычлы затларына һәм финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләренә билгеләнгән үрнәктәге таныклыклар бирә;

8) барлык кандидатлар, сәяси партияләр өчен федераль законнарда, әлеге Кодекста билгеләнгән сайлау алды эшчәнлеге шартларының үтәлешен тәэмин итә;

9) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча хәбәрләрен тыңлый;

10) бюллетеньнәрнең рәвешен һәм текстын, бюллетеньнәрнең санын, шулай ук аларны әзерләүне тикшереп тору тәртибен билгели;

11) сайлаучылар исемлегенең һәм башка сайлау документларының рәвешен билгели, аларны әзерләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итә;

12) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыгының текстын билгели, күрсәтелгән бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне һәм сайлау комиссияләрендә аларны булдыруны тәэмин итә;

13) сайлау комиссияләре мөһерләренең үрнәкләрен раслый;

14) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны, сайлау комиссияләренең эшчәнлеген һәм аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акчаларны бүлә, күрсәтелгән акчаларның, шулай ук

кандидатларның сайлау фондларына кергән акчаларның максатчан файдаланышын тикшереп тора;

15) сайлау алды агитациясен уздыру өчен эфир вакытын һәм матбугат мәйданын бүлүнең бердәм тәртибен оештыру чараларын күрә;

16) тавыш бирү йомгакларын билгеләүнең, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның гомуми нәтиҗәләрен билгеләүнең бердәм тәртибен, шулай ук тавыш бирү йомгакларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгару тәртибен оештыру чараларын күрә;

17) сайлау комиссияләренең биналар, транспорт чаралары, элемтә чаралары белән тәэмин ителешен тикшереп тора һәм сайлауларны матди-техник тәэмин итүнең башка мәсьәләләрен карый;

18) сайлау гамәлләрен тормышка ашыруның вакытлары һәм тәртибе, сайлау кампаниясенең барышы турында сайлаучыларга хәбәр итүне тәэмин итә;

19) түбәнгерәк сайлау комиссияләренең һәм аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый, шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

20) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгели, теркәлгән кайсы кандидатның Татарстан Республикасы Президенты булып сайланганлыгын билгели һәм аңа сайлану турында таныклык бирә;

21) Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча кабат тавыш бирүне билгели;

22) Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлауларны билгели;

23) әлеге Кодекс, башка законнар нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

$104^9$ статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда территория комиссияләре вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда территория комиссияләре:

1) тиешле территориядә гражданнарның сайлау хокуклары үтәлешен тикшереп тора;

2) тиешле территориядә участок комиссияләре өчен технологик җиһазларның (тавыш бирү кабиналары, тавыш бирү әрҗәләре) нормативлары үтәлешен тәэмин итә;

3) тиешле территориядә Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле гамәлләрнең үтәлешен тәэмин итә;

4) тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын билгеләүнең бердәм тәртибен үтәү чараларын күрә, тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын билгели;

5) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны финанс ягыннан тәэмин итү өчен үзенә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән акчаларны бүлә, күрсәтелгән акчаларның максатчан файдаланышын тикшереп тора;

6) түбәнгерәк участок сайлау комиссияләренә методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

7) Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча участок комиссияләрен төзи һәм аларның рәисләрен билгеләп куя;

8) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча хәбәрләрен тыңлый;

9) тиешле территориядә участок комиссияләре эшен җайга сала, әлеге комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

10) әлеге Кодексның 28 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләрендә каралган очраклардан гайре, һәр сайлау участогы буенча аерым-аерым сайлаучылар исемлекләрен төзи, сайлаучылар турындагы белешмәләрне төгәлләштерә;

11) сайлау гамәлләрен башкару вакытлары һәм тәртибе, сайлау кампаниясе барышы турында сайлаучыларга мәгълүмат бирә;

12) тиешле территориядә сайлаучыларга мәгълүмат бирү, сайлау алды агитациясен үткәрү тәртибен үтәүне тикшереп тора;

13) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле бюллетеньнәрне һәм башка документларны сайлау участокларына илтеп тапшыруны оештыра;

14) сайлаучыларга бүтән сайлау участокларында тавыш бирү таныклыкларын бирә;

15) билгеләнгән тәртип нигезендә тиешле территориядә «Сайлаулар» ДАСтан файдалануны тәэмин итә;

16) сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә яисә тиешле архив учреждениесенә тапшыруны тәэмин итә яки күрсәтелгән документларны аларны саклау вакытлары тәмамланганнан соң юкка чыгара;

17) тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын билгели һәм игълан итә;

18) әлеге Кодекс, башка законнар нигезендә бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

104[10] статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда участок комиссияләре вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда участок комиссияләре әлеге Кодексның 16 статьясындагы 7 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

16[3] бүлек. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү**

104[11] статья. **Территория комиссияләре тарафыннан тавыш бирү йомгакларын билгеләү**

1. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсе участок комиссиясе тарафыннан тиешле территория комиссиясенә җибәрелә.

2. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләренең әлеге беркетмәләре нигезендә территория комиссиясе тавыш бирү көненең иртәгесеннән дә соңга калмыйча тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын билгели.

3. Тавыш бирү йомгаклары буенча территория комиссиясе тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, аларга түбәндәгеләр кертелә:

1) тиешле территориядә участок комиссияләре саны турында күрсәткечләр;

2) тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләреннән кергән беркетмәләр саны турындагы күрсәткечләр,

алар нигезендә тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссиясе беркетмәсе төзелә;

3) әлеге Кодексның 78 статьясындагы 2, 3 һәм 5 өлешләрендә билгеләнгән тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең барлык юллары буенча кушылган күрсәткечләр.

4. Тиешле беркетмәнең һәр нөсхәсенә түбәндәгеләр кушып бирелә:

1) тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләреннән алынган барлык беркетмәләрдәге күрсәткечләрне тулысынча кертеп, тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблица;

2) территория комиссиясе тарафыннан сайлау бюллетеньнәре алу турында, аларны участок комиссияләренә тапшыру турында, шулай ук территория комиссиясендә сакланган файдаланылмаган сайлау бюллетеньнәрен, аларның санын күрсәтеп, юкка чыгару турында актлар;

3) территория комиссиясе тарафыннан сайлаучыларга бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыкларын бирү турында, аларны участок комиссияләренә тапшыру турында, шулай ук бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларының өзмә талоннарын, аларның санын күрсәтеп, юкка чыгару турында (кабат тавыш бирүне үткәргәндә – бүтән сайлау участогында тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларын, әлеге таныклыкларның санын һәм номерларын күрсәтеп, юкка чыгару турында) актлар.

5. Тавыш бирү йомгаклары турында территория сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе, имзаланганнан соң, аңа кушып бирелә торган документлары белән бергә кичекмәстән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә һәм территория комиссиясенә кире кайтарылмый.

### $104^{12}$ статья. **Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү**

1. Тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләрендәге күрсәткечләр нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, тавыш бирү көненнән соң җиде көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгели.

2. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 50 проценттан күбрәк тавышын җыйган теркәлгән кандидат сайланган дип танылa. Тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саны тавыш бирү тартмаларындагы билгеләнгән рәвештәге сайлау бюллетеньнәре саны буенча билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан түбәндәге очракларда булмаган дип танылa:

1) гомуми сайлауларда бюллетеньгә ике кандидат кертелеп, шуларның берсе дә тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышының яртысыннан күбрәген алмаса;

2) бер кандидатура буенча кабат тавыш бирү үткәрелсә һәм тиешле кандидат өчен тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 50 проценттан кимрәге тавыш бирсә;

3) кабат тавыш бирүне уздырганда барлык кандидатлар да китсә.

4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турында беркетмә төзи, аңа түбәндәге белешмәләр кертелә:

1) территория комиссияләре саны;

2) территория комиссияләренең әлеге беркетмәне төзүгә нигез булган беркетмәләре саны;

3) тавыш бирү йомгаклары турында территория комиссияләренең беркетмәләрендәге барлык юлларның суммар күрсәткечләре;

4) тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар санынннан һәр кандидат өчен хуплап бирелгән тавышлар өлеше (процентларда);

5) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашкан сайлаучылар саны һәм сайлаучылар исемлекләренә кертелгән сайлаучылар санынннан әлеге санның өлеше (процентларда);

6) Татарстан Республикасы Президенты булып сайланган теркәлгән кандидатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме.

### $104^{13}$ статья. **Сайланган Татарстан Республикасы Президентын теркәү**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмә имзаланганнан соң бу хакта Татарстан Республикасы Президенты булып сайланган теркәлгән кандидатка кичекмәстән хәбәр итә, шуннан соң Татарстан Республикасы Президенты хәбәрнамә алган көннән биш

көн эчендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы Президенты статусына туры килми торган вазыйфаларыннан азат ителү турындагы боерык (бүтән документ) күчермәсен йә хәбәрнамә алган көннән өч көн эчендә мондый вазыйфалардан азат ителүен сорап язган гаризасын бирүне раслаучы документ күчермәсен тапшыра.

2. Әгәр Татарстан Республикасы Президенты булып сайланган теркәлгән кандидат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган таләпләрне үтәмәсә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мондый кандидатны сайланган дип тану турындагы үз карарын юкка чыгара.

3. Әгәр әлеге статьяның 1 өлешендә каралган таләпне кандидат әлеге Кодексның 53 статьясындагы 8 өлешендә каралган мәҗбүр итәрлек сәбәпләрдән башка үтәмәсә, шуның нәтиҗәсендә кабат сайлаулар билгеләнсә, бу кандидат тиешле сайлау комиссияләренең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән кабат сайлаулар үткәрүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарын тулысынча кире кайтарырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сайлауларның гомуми нәтиҗәләре рәсми бастырып чыгарылганнан һәм Татарстан Республикасы Президенты булып сайланган теркәлгән кандидат әлеге статьяның 1 өлешендә каралган таләпләрне үтәгәннән соң аны терки һәм аңа Татарстан Республикасы Президенты булып сайлануы турында таныклык бирә.

104[14] статья. **Тавыш бирү йомгакларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгару һәм халыкка җиткерү**

1. Комиссия һәр сайлау участогы, шушы комиссия эшчәнлеге кагыла торган территория буенча тавыш бирү йомгакларын, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен шушы сайлау комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсендәге һәм турыдан-туры түбәнгерәк комиссияләрнең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендәге күрсәткечләр күләмендә сайлаучыларга, кандидатларга, кандидатларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, чит ил (халыкара) күзәтүчеләренә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә аларның таләпләре буенча танышу өчен бирә.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләрен

билгеләгәннән соң бер тәүлек эчендә массакүләм мәгълүмат чараларына сайлаулар нәтиҗәләре турындагы гомуми күрсәткечләрне җибәрә, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашкан сайлаучылар саны һәм сайлаучылар исемлекләренә кертелгән сайлаучылар саныннан шушы сан өлеше (процентларда);

2) тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саныннан һәр кандидат өчен бирелгән тавышларның өлеше (процентларда);

3) Татарстан Республикасы Президенты булып сайланган кандидатның фамилиясен, исемен һәм атасының исемен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турында яисә сайлауларны булмаган йә гамәлгә яраксыз дип тану турында комиссия карары.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, тавыш биргән көннән ике атнадан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен дәүләтнең вакытлы матбугат басмаларында рәсми бастырып чыгара, монда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашкан сайлаучылар саны һәм сайлаучылар исемлекләренә кертелгән сайлаучылар саныннан шушы сан өлеше (процентларда);

2) һәр кандидат алган сайлаучылар тавышлары саны, шул исәптән тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саныннан процентларда;

3) сайланган Татарстан Республикасы Президенты турында әлеге Кодексның 75 статьясындагы 6 өлешенең 1 – 4, 6 һәм 7 пунктларында каралган күрсәткечләрне күрсәтеп, Татарстан Республикасы Президентын сайлау турында йә сайлауларны булмаган яисә гамәлгә яраксыз дип тану турында мәгълүмат.

4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тавыш бирү көненнән ике ай эчендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәсендәге һәм тавыш бирү йомгаклары турында түбәнгерәк комиссияләр беркетмәләрендәге, шулай ук сайланган Татарстан Республикасы Президенты турында әлеге Кодексның 75 статьясындагы 6 өлешендә каралган тулы күрсәткечләрне рәсми бастырып чыгара. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турында тулы күрсәткечләр рәсми басылып чыккан көннән өч ай эчендә шушы күрсәткечләр Татарстан Республика-

сы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

## 16[4] бүлек. **Кабат тавыш бирү. Кабат сайлаулар.**

### 104[15] статья. **Кабат тавыш бирү**

1. Кабат тавыш бирү «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Кодекс таләпләре нигезендә әлеге статьяда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, әгәр Татарстан Республикасы Президентын гомуми сайлауларда бюллетеньгә икедән артык теркәлгән кандидат кертелеп, аларның берсе дә Татарстан Республикасы Президентын гомуми сайлаулар нәтиҗәләре буенча сайлау өчен кирәкле сайлаучылар тавышын алмаган очракта үткәрелә. Кабат тавыш бирү сайлаучыларның аеруча күп тавышын җыйган теркәлгән ике кандидат буенча, һәр теркәлгән кандидатның үз кандидатурасы буенча кабат тавыш бирү үткәрүгә ризалыгы турында язма гаризасы булса гына уздырыла.

3. Кабат тавыш бирү Татарстан Республикасы Президентын гомуми сайлауларда тавыш биргән көннән алып 21 көн узгач үткәрелә. Кабат тавыш бирүне үткәрү турындагы хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тиешле карар кабул иткән көннән ике көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

4. Әгәр кабат тавыш бирүне уздырганчыга кадәр кабат тавыш бирү үткәрелергә тиешле теркәлгән кандидатларның берсе үз кандидатурасын кире алса яисә башка сәбәпләр аркасында китсә, аның урыны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча теркәлгән кандидат алган тавышлар саны буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе башта кабат сайлауны билгеләгән кандидатуралардан соң икенчесенә тапшырыла, күрсәтелгән теркәлгән кандидатның үз кандидатурасы буенча кабат тавыш бирүне үткәрүгә ризалыгы турында язма гаризасы булырга тиеш. Мондый гариза башта кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидат киткән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш. Бу очракта кабат тавыш бирү әлеге Кодексның 53 статьясындагы 1 өлеше нигезендә гариза биргән

көннән алып йә башка сәбәпләр аркасында киткән көннән алып 14 көн узгач беренче якшәмбедә үткәрелә.

5. Кабат тавыш бирү үткәрелгәндә кандидатуралары буенча кабат тавыш бирү үткәрелми торган теркәлгән кандидатлар Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү датасын билгеләгән көннән үз статусларын югалталар. Монда әлеге статьяның 4 өлешендә каралган очракта, киткән теркәлгән кандидат урынын биләгән теркәлгән кандидат теркәлгән кандидат статусына бәйле хокукларга һәм бурычларга кабат ия була.

6. Кабат тавыш бирү үткәрелгәндә агитация чоры Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кабат тавыш бирү көнен билгеләгән көннән яңартыла.

7. Кабат тавыш бирү йомгаклары буенча тавыш биргәндә сайлаучылар тавышы саны буенча башка кандидатка караганда сайлаучыларның күпчелек тавышын алган кандидат сайланган дип санала.

8. Кабат тавыш бирү, әгәр теркәлгән кандидатлар киткәннән соң бер генә теркәлгән кандидат калса, бер генә кандидатура буенча да үткәрелергә мөмкин. Монда теркәлгән кандидат, әгәр тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар тавышының кимендә 50 процентын алса, сайланган дип санала.

104[16] статья. **Кабат сайлаулар**

1. Әгәр Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар булмаган яисә гамәлгә яраксыз дип танылса йә сайланган кандидат Татарстан Республикасы Президенты статусына туры килмәслек вәкаләтләреннән баш тартмаса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлауларны билгели. Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көненнән өч көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

2. Әгәр Татарстан Республикасы Президентын төп сайлаулар мартның икенче якшәмбесендә уздырылса һәм аларның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты сайланмаса, Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар Татарстан Республикасы Президентын төп сайлаулар уздырылган елда октябрь аеның икенче якшәмбесендә, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны уздырган елда – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә уздырыла. Әгәр төп сайлаулар Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату-

га бәйле рәвештә билгеләнгән булса, кабат сайлауларны уздыру өчен нигез барлыкка килгән көннән дүрт айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар уздырыла. Калган очракларда Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар мартның икенче якшәмбесендә йә октябрьнең икенче якшәмбесендә уздырыла, ә чираттагы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар уздыру елында – шушы сайлауларда тавыш бирү көнендә, әмма кабат сайлаулар уздыру өчен нигез барлыкка килгәннән соң бер елдан да соңга калмыйча уздырыла.

3. Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар уздырганда сайлау гамәлләренең вакытлары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән өчтән бергә кыскартылырга мөмкин.

4. Участок комиссияләренең вәкаләтләре чоры беткәнче үк Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлаулар билгеләнгән булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе йә участок комиссияләренең вәкаләтләре чорын озайту турында, йә участок комиссияләрен яңа составта төзү турында күрсәтмә бирергә тиеш.»;

40) 106 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«106 статья. **Муниципаль сайлауларны финанслау**

1. Муниципаль сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле гамәлләрне финанслау җирле бюджетлар акчалары исәбеннән башкарыла.

2. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар уздырганда кандидатлар һәм сайлау берләшмәләре сайлау фондлары төзергә тиеш, моңа федераль законнарда, әлеге Кодекста билгеләнгән очраклар керми.

3. Депутатлыкка кандидатларның сайлау фондлары, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзалары түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарының иң чик суммасының 50 процентыннан артык була алмый;

2) кандидатны күрсәткән сайлау берләшмәсе тарафыннан кандидатка бүлеп бирелгән акчалар, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының әлеге статьяның 4

өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарының иң чик суммасының 50 процентыннан артык була алмый;

3) гражданнарның ирекле иганәләре, аларның күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының һәр граждан өчен әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарның иң чик суммасының 2,5 процентыннан артмый;

4) юридик затларның ирекле иганәләре, аларның күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының һәр юридик зат өчен әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарның иң чик суммасының 50 процентыннан артмый.

4. Депутатлыкка кандидатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 600 мең сумнан, ә кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатлар өчен 720 мең сумнан арта алмый.

5. Муниципаль сайлауларда кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренең сайлау фондлары, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасына кандидатның сайлау фонды түбәндәгеләр исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең үз акчалары, кандидатның үз акчалары, аларның гомуми күләме сайлау берләшмәсе сайлау фондының, кандидатның әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән акчаларының барлык чыгымнарының иң чик суммасының 50 процентыннан, ә кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатлар өчен 75 процентыннан артык була алмый;

2) кандидатны күрсәткән сайлау берләшмәсе кандидатка бүлеп бирелгән акчалар, аларның гомуми күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарының иң чик суммасының 50 процентыннан артык була алмый;

3) гражданнарның ирекле иганәләре, аларның күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының һәр граждан өчен әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарның иң чик суммасының 0,5 процентыннан артмый;

4) юридик затларның ирекле иганәләре, аларның күләме кандидатның сайлау фонды акчаларының һәр юридик зат өчен әлеге статьяның 6 өлеше нигезендә билгеләнгән барлык чыгымнарның иң чик суммасының 5 процентыннан артмый.

6. Муниципаль сайлауларда кандидатлар исемлеген күрсәткән сайлау берләшмәсенең сайлау фонды, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасына кандидатның сайлау фонды акчаларын тотуның иң чик күләме – 6 миллион сумнан,

ә җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасына кабат тавыш бирү билгеләнгән кандидатлар өчен 7 200 000 сумнан арта алмый.

7. Сайлау фондларының әлеге статьяның 4 һәм 6 өлешләрендә билгеләнгән акчаларын халык саны 100 000нән 500 000гә кадәр булган муниципаль берәмлекләрдә җирле үзидарә органнарына сайлаулар үткәргәндә тотуның иң чик күләме ике тапкырга, ә 30 000нән 100 000гә кадәр булганда өч тапкырга, 10 000нән 30 000гә кадәр булганда биш тапкырга, 1 000нән 10 000гә кадәр булганда җиде тапкырга кими, 1 000нән кимрәк булганда ун тапкырга киметелә.»;

41) 114 статьяның 9 өлешендәге 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

42) 125 статьяда:

а) «Кандидатлар» сүзен «1. Кандидатлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасын биләгән һәм әлеге вазыйфадан үз теләге белән, шул исәптән аны депутат итеп сайлауга йә вазыйфаи биләве муниципаль берәмлек башлыгы статусына туры килми торган башка сайланулы вазыйфага сайлануына бәйле рәвештә отставкага киткән йә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасыннан җибәрелгән граждан күрсәтелгән сәбәпләргә бәйле рәвештә билгеләнгән сайлауларда кандидат булып күрсәтелә алмый.»;

43) $128^1$ статьяның 8 – 10 өлешләрен үз көчләрен югалткан дип танырга;

44) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче кушымта

# ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

______________________________________________сайлаулар
*(муниципаль берәмлек уставы нигезендә вазыйфаның һәм җирле үзидарәнең сайланулы органының исеме)*[1]

________елның ________________
*(тавыш бирү датасы)*

Без, түбәндә имза салучылар, ____________________________ номерлы
*(үз-үзен күрсәтү яисә, сайлау берләшмәсе исемен күрсәтеп, сайлау*
______________________________________________________
*берләшмәсеннән күрсәтелү)*
күрсәтелгән җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына ______________________________ сайлау
*(сайлау округы исеме яисә номеры)*
округыннан кандидат __________ __________туган,_______________
*(гражданлыгы)* *(туган көне)*
_____________________________________________________эшләүче,
*(эш урыны, били торган вазыйфасы яисә шөгыленең төре, әгәр кандидат депутат булып торса һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармаса, – бу хакта белешмәләр тиешле вәкиллекле орган исемен күрсәтеп бирелә)*
______________________________________________________ яшәүче
*(яшәү урыны урнашкан Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункты исеме)*
__________________________________________________хуплыйбыз.
*(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

| № | Фамилия-се, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшендә – туган көне һәм ае өстәмә рәвештә) | Яшәү урыны адресы | Паспортының яисә аны алыштыручы документының се-риясе һәм номеры, бирү датасы | Имза һәм аны салу датасы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| ... | | | | | |

Имзалар кәгазен таныклыйм: ______________________________
*(имзаларны җыйган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урынының адресы, паспортының яисә граждан паспортын алыштыручы документының, аны бирү датасын, аны биргән органның исемен яисә кодын күрсәтеп, номеры һәм сериясе, аның имзасы һәм аны салу датасы)*
Кандидат:
______________________________________________________
*(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, үз кулы белән салган имзасы һәм аны кертү датасы)*

**Искәрмә.** Имзалар кәгазендә белешмәләре күрсәтелгән кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булса, имзалар кәгазендә кандидатның атасы исеменнән соң кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр күрсәтелә. Әгәр имзалар кәгазендә белешмәләр булган кандидат сайланырга ризалык бирүе турындагы гаризасында Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 39 статьясындагы 2 өлеше һәм 41 статьясындагы 2 өлеше нигезендә үзенең сәяси партиягә йә башка иҗтимагый берләшмәгә каравын һәм әлеге сәяси партиядә йә әлеге иҗтимагый берләшмәдә үзенең статусын күрсәтсә, бу хакта белешмәләр имзалар кәгазендә кандидатның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән соң яисә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләрдән соң күрсәтелә.

______________

[1] Сызыклар астындагы текст, шулай ук искәрмә һәм сноска әзерләнгән имзалар кәгазендә күренмәскә дә мөмкин.»;

45) түбәндәге эчтәлекле 10 нчы кушымта өстәргә:

«10 нчы кушымта

**ХУПЛАУ КӘГАЗЕ**

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар

________елның ___________________
*(тавыш бирү датасы)*[1]

Мин,_____________________________________________________________
*(затның статусы: вәкиллекле орган исемен күрсәтеп,*

_________________________________________________________________
*муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, вазыйфасы исемен күрсәтеп, шулай ук муниципаль берәмлек исемен күрсәтеп, муниципаль берәмлек башлыгы)*

____________________,___________________________________________
*(туган көне)* *(фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

сәяси партия (яисә аның региональ бүлекчәсе) тарафыннан күрсәтелгән Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат ________

_________________________________________________________________
*(эш яисә хезмәт урыны, били торган вазыйфасы яисә шөгыльләренең төре)*

__________________________________________________________ эшләүче,

____________________________________________________________ яшәүче
*(яшәү урыны урнашкан Россия Федерациясе субъекты, район, шәһәр, башка торак пункты исеме)*

___________________________________________________________хуплыйм
*(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Имза | Имза салу датасы | Имза салу вакыты |
|---|---|---|---|
| | | | |

Имзаның дөреслеген таныклау турында нотариусның таныклау язуы

**Искәрмә.** Кандидатны хуплау кәгазендә белешмәләре күрсәтелә торган кандидатның кире алынмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган очракта кандидатны хуплау кәгазендә кандидатның атасы исеменнән соң кандидатның хөкем ителүе турында белешмәләр күрсәтелә. Әгәр кандидатны хуплау кәгазендә белешмәләр булган кандидат сайланырга ризалык бирүе турындагы гаризасында Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 42 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә үзенең сәяси партиягә йә башка иҗтимагый берләшмәгә каравын һәм әлеге сәяси партиядә йә әлеге иҗтимагый берләшмәдә үзенең статусын күрсәтсә, бу хактагы белешмәләр кандидатны хуплау кәгазендә кандидатның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән соң яисә кандидатның хөкем ителүе турындагы белешмәләрдән соң күрсәтелә.

[1] Сызыклар астындагы текст, шулай ук искәрмә һәм сноска әзерләнгән кандидатны хуплау кәгазендә күренмәскә дә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 22 июне
№ 41-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 767. «2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«2012 елга, 2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2011 елның 30 ноябрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 кушымтасындагы 1 нче таблицасына (Ватаным Татарстан, 2011, 3 декабрь; 2012, 1 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1) «Финанслашу фонды | 713 | 05 | 01 | 0980201 | 010 | 1 373 131,0» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән «2010 - 2015 елларга һәм перспективада 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» озак сроклы максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру | 713 | 05 | 01 | 0980201 | 010 | 1 108 984,2»; |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2) «Капиталь ремонт | 713 | 05 | 03 | 5245100 | 601 | 110 083,7» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән «2010 - 2015 елларга һәм перспективада 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» озак сроклы максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру | 713 | 05 | 03 | 5245100 | 601 | 110 083,7»; |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3) «Дәүләт учреждениеләре тарафыннан функцияләр башкару | 723 | 01 | 13 | 0929902 | 001 | 8 939,3» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән «2010 - 2015 елларга һәм перспективада 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» озак сроклы максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру | 723 | 01 | 13 | 0929902 | 001 | 8 890,4»; |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4) «Дәүләт учреждениеләре тарафыннан функцияләр башкару | 755 | 01 | 13 | 0929902 | 001 | 7 030,7» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән «2010 - 2015 елларга һәм перспективада 2020 елга кадәр Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» озак сроклы максатчан программасы чараларын гамәлгә ашыру | 755 | 01 | 13 | 0929902 | 001 | 7 030,7». |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 22 июне
№ 42-ТРЗ